ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

28 декабрь 2021 ел № 8504

Муниципаль милектәге җир участогын сатулар үткәрмичә милеккә, арендага, даими (сроксыз) файдалануга, түләүсез файдалануга бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында

Россия Федерациясе Җир кодексы, «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 елның 13 апрелендәге 242 номерлы карары, Башкарма комитетның «Муниципаль һәм дәүләт хезмәтләре исемлеген раслау турында» 2016 елның 13 маендагы 2363 номерлы карары

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Муниципаль милектәге җир участогын сатулар үткәрмичә милеккә, арендага, даими (сроксыз) файдалануга, түләүсез файдалануга бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын кушымтада каралганча расларга.

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны «Челнинские известия», «Шәһри Чаллы» газеталарында бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитетның җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр идарәсе башлыгы Л.Р. Гыйззәтуллинга йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе

Ф.Ш. Салахов

Башкарма комитетның
2021 елның 28 декабрендәге
8504 номерлы карарына
кушымта

Муниципаль милектәге җир участогын сатулар үткәрмичә милеккә, арендага, даими (сроксыз) файдалануга, түләүсез файдалануга бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты

1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (алга таба – Регламент) муниципаль милектәге җир участогын сатулар үткәрмичә милеккә, арендага, даими (сроксыз) файдалануга, түләүсез файдалануга бирү буенча муниципаль хезмәт (алга таба – муниципаль хезмәт) күрсәтү стандартын һәм тәртибен билгели.

Регламент нигезләмәләре шулай ук дәүләт милке чикләнмәгән җир участокларына карата һәм җир участогын арендалау шартнамәсенә үзгәрешләр керткән, аны өзгән яки яңаны төзегән очракларда кулланыла. Җир участогын арендалау шартнамәсенең срогы Россия Федерациясе Җир кодексының 39.8 статьясы нигезендә билгеләнә.

1.2. Муниципаль хезмәттән файдаланучылар: физик һәм юридик затлар (алга таба – гариза бирүче).

Гариза бирүчеләрнең мәнфәгатьләрен билгеләнгән тәртиптә гариза бирүче тарафыннан вәкаләтләнгән затлар һәм физик затларның законлы вәкилләре (алга таба – гариза бирүченең вәкиле) якларга мөмкин.

Гариза бирүченең муниципаль хезмәт алуга хокукын раслый торган нигезләрнең һәм документларның тулы исемлеге әлеге Регламентның 1 нче кушымтасында китерелгән.

1.3. Муниципаль хезмәт күрсәтү турында мәгълүмат бирү:

1.3.1. муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибе турында мәгълүмат урнаштырыла:

1) дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча күпфункцияле үзәкләр бүлмәләрендә урнашкан муниципаль хезмәт турында визуаль һәм текстлы мәгълүматны үз эченә алган мәгълүмат стендларында;

2) «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында (https://www. nabchelny.ru);

3) Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында (https://uslugi.tatarstan.ru/) (алга таба – Республика порталы);

4) Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталында (https://www.gosuslugi.ru/) (алга таба – Бердәм портал);

5) «Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр реестры» дәүләт мәгълүмат системасында (http://frgu.tatar.ru) (алга таба – Республика реестры).

1.3.2. Муниципаль хезмәт күрсәтү мәсьәләләре буенча консультация бирү гамәлгә ашырыла:

1) телдән мөрәҗәгать иткәндә дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча күпфункцияле үзәкләрдә – шәхсән яки телефон аша;

2) Республика порталының интерактив формасында;

3) Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетында (алга таба – Орган):

телдән мөрәҗәгать иткәндә – шәхсән яки телефон аша;

язмача (шул исәптән электрон документ формасында) мөрәҗәгать иткәндә – кәгазьдә почта аша, электрон формада электрон почта (uzioIP@yandex.ru) аша.

1.3.3. Бердәм порталда, Республика порталында Республика реестрындагы мәгълүматлар нигезендә муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибе һәм сроклары турында мәгълүмат гариза бирүчегә бушлай бирелә.

Муниципаль хезмәт күрсәтү сроклары һәм тәртибе турындагы мәгълүматтан файдалану, гариза бирүче тарафыннан нинди дә булса таләпләрне үтәмичә, шул исәптән аны гариза бирүченең техник чараларына урнаштыру түләү алу, теркәлү яки авторлаштыруны, яки аларга персональ мәгълүматлар бирүне күздә тотучы программа белән тәэмин итү хокукына ия зат белән лицензияле яки башка килешү төзүне таләп итә торган программа тәэминатыннан файдаланмыйча гамәлгә ашырыла.

1.3.4. Гариза бирүче шәхсән яки телефон аша мөрәҗәгать иткәндә, кергән мөрәҗәгать нигезендә түбәндәге мәгълүмат бирелә:

1) дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча күпфункцияле үзәкнең, Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының урнашу урыны (адрес, эш графигы, белешмә телефоннары) турында;

2) муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибе турында, гаризалар бирү ысуллары һәм сроклары турында;

3) муниципаль хезмәт күрсәтелә торган гражданнар категорияләре турында; муниципаль хезмәт күрсәтү мәсьәләләрен җайга салучы норматив хокукый актлар турында;

4) муниципаль хезмәт күрсәтү турында гаризаны карап тикшерү өчен кирәкле документлар исемлеге турында, гаризаны кабул итү һәм теркәү сроклары турында;

5) муниципаль хезмәт күрсәтү барышы турында;

6) муниципаль хезмәт күрсәтү мәсьәләләре буенча рәсми сайтта мәгълүмат урнаштыру урыны турында;

7) Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты вазыйфаи затларының гамәлләренә яки гамәл кылмавына шикаять бирү тәртибе турында.

Язма мөрәҗәгать буенча муниципаль хезмәт күрсәтү өчен җаваплы бүлекнең хезмәткәрләре гариза бирүчегә муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибен һәм Регламентның әлеге пунктында күрсәтелгән мәсьәләләрне язма рәвештә тулырак аңлаталар һәм, мөрәҗәгатьне теркәгәннән соң өч эш көне эчендә, гариза бирүчегә җавап җибәрәләр. Җаваплар мөрәҗәгать телендә бирелә. Мөрәҗәгать телендә җавап бирү мөмкин булмаган очракта, Татарстан Республикасының дәүләт телләре кулланыла.

1.3.5. Муниципаль хезмәт күрсәтү мәсьәләләре буенча мәгълүмат Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында һәм гариза бирүчеләр белән эшләү өчен, Башкарма комитет бүлмәләрендәге мәгълүмат стендларында урнаштырыла.

Мәгълүмат стендларында һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә муниципаль районның рәсми сайтында урнаштырыла торган Татарстан Республикасы дәүләт телләрендәге мәгълүмат Регламентның 2.1, 2.3, 2.4, 2.5, 2.7, 2.9, 2.10, 2.11, 5.1 пунктларындагы муниципаль хезмәт турында мәгълүматны Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетның урнашу урыны, белешмә телефоннары, эш вакыты, муниципаль хезмәт күрсәтүгә гаризалар кабул итү графигы турында мәгълүматны үз эченә ала.

1.4. Муниципаль хезмәт күрсәтүне җайга салучы норматив хокукый актлар исемлеге (норматив хокукый актлар реквизитларын һәм аларны рәсми бастырып чыгару чыганакларын күрсәтеп) Бердәм порталда, Республика реестрында,

«Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә рәсми сайтта, урнаштырылган.

Административ регламентның гамәлдәге редакциядәге тексты «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә муниципаль районның рәсми сайтында, Республика реестрында урнаштырылырга тиеш.

1.5. Регламентта түбәндәге терминнар һәм билгеләмәләр кулланыла:

дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча күпфункцияле үзәкнең читтәге эш урыны – Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча күпфункцияле үзәкләр эшчәнлеген оештыру кагыйдәләрен раслау турында» 2012 елның 22 декабрендәге 1376 номерлы карары белән расланган Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча күпфункцияле үзәкләр эшчәнлеген оештыру кагыйдәләренең 34 пункты нигезендә Татарстан Республикасы муниципаль районының шәһәр (авыл) җирлегендә яки шәһәр округында төзелгән дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча күпфункцияле үзәкнең территориаль аерымланган структур бүлекчәсе (офисы);

техник хата – муниципаль хезмәт күрсәтүче орган тарафыннан җибәрелгән һәм документка (муниципаль хезмәт нәтиҗәсенә) кертелгән мәгълүматларның бу мәгълүматларны кертүгә нигез булган документлардагы мәгълүматларга туры килмәвенә китергән хата (язудагы хата, басмадагы хата, грамматик яки арифметик хата яисә шуңа охшаш хата).

ЕСИА – электрон формада дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен файдаланыла торган мәгълүмат системаларының мәгълүмати-технологик хезмәттәшлеген тәэмин итә торган инфраструктурада Бердәм идентификация һәм аутентификация системасы.

Мәгълүмати хезмәттәшлектә катнашучыларның (гариза бирүче гражданнарның һәм башкарма хакимият органнары һәм җирле үзидарә органнары вазыйфаи затларының) дәүләт мәгълүмат системаларында һәм башка мәгълүмат системаларында булган мәгълүматтан файдалану мөмкинлеген тәэмин итә торган федераль дәүләт мәгълүмат системасы;

КФҮ – «Татарстан Республикасында дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча күпфункцияле үзәк» дәүләт бюджет учреждениесе;

КФҮ АМС – Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча күпфункцияле үзәкләренең автоматлаштырылган мәгълүмат системасы.

Регламентта муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза (алга таба - гариза) дигәндә «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның (алга таба – 210-ФЗ номерлы Федераль закон) 2 статьясының 3 пункты нигезендә бирелгән муниципаль хезмәт күрсәтү турында запрос аңлашыла.

## 2. Муниципаль хезмәт күрсәтү стандарты

### 2.1. Муниципаль хезмәтнең исеме

Муниципаль милектәге җир участогын сатулар үткәрмичә милеккә, арендага, даими (срокcыз) файдалануга, түләүсез файдалануга бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты

### 2.2. Турыдан-туры муниципаль хезмәт күрсәтүче җирле үзидарә башкарма-боеру органының исеме

Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты

## 2.3. Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсенең тасвирламасы

2.3.1. Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе булып тора:

1) җир участогын сату-алу шартнамәсе проекты (алга таба - сату-алу шартнамәсе) (әлеге Регламентка 2 нче кушымта, сату-алу шартнамәсе формасын теркәргә);

2) җир участогын арендалау шартнамәсе проекты (алга таба - аренда шартнамәсе) (әлеге Регламентка 3 нче кушымта, аренда шартнамәсе формасын теркәргә);

3) җир участогыннан түләүсез файдалану шартнамәсе проекты (алга таба-түләүсез файдалану шартнамәсе) (әлеге Регламентка 4 нче кушымта, түләүсез файдалану шартнамәсе формасын теркәргә);

4) җир участогын даими (сроксыз) файдалануга бирү турында карар (әлеге Регламентка 6 нчы кушымта);

5) муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту турында карар (әлеге Регламентка 7 нче кушымта).

2.3.2. Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе гариза бирүчегә «Электрон имза турында» 2011 елның 6 апрелендәге 63-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 63-ФЗ номерлы Федераль закон) нигезендә, Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты вәкаләтле вазыйфаи затының (яисә Органның) көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзаланган электрон документ формасында Республика порталының шәхси кабинетына җибәрелә.

2.3.3. Гариза бирүченең теләге буенча, Регламентның 2.3.1. пунктының 1-4 пунктчаларында күрсәтелгән, Органның вәкаләтле вазыйфаи заты тарафыннан имзаланган һәм Органның мөһере белән расланган кәгазьдәге муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе гариза бирүчегә Органда яки КФҮдә бирелә.

Регламентның 2.3.1. пунктының 5, 6 пунктчаларында күрсәтелгән муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе электрон документның кәгазьдә бастырып чыгарылган һәм, Органның мөһере һәм вәкаләтле вазыйфаи затының яки КФҮ хезмәткәренең имзасы белән расланган нөсхәсе формасында Органда яки КФҮдә бирелә.

2.3.4. Гариза бирүче муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен электрон документ формасында муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсенең гамәлдә булу срогы дәвамында алырга хокуклы.

2.3.5. Гариза бирүче шартнамәне имзалаган көннән башлап биш эш көненнән дә артмаган срокта Орган килешүне дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенә (Росреестр) җибәрә.

## 2.4. Муниципаль хезмәт күрсәтү срогы, шул исәптән муниципаль хезмәт күрсәтүдә катнашучы оешмаларга мөрәҗәгать итү кирәклеген исәпкә алып, туктату мөмкинлеге Россия Федерациясе законнарында каралган очракта, муниципаль хезмәт күрсәтүне туктату срогы, муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе булган документларны бирү (җибәрү) срогы

2.4.1. Муниципаль хезмәт күрсәтү срогы 22 эш көне тәшкил итә.

Россия Федерациясе Җир Кодексының 39.18 статьясы белән каралган тәртиптә җир участогы биреләчәге турында хәбәр бастырып чыгарырга кирәк булган очракта муниципаль хезмәт күрсәтүнең максималь срогы 55 эш көне тәшкил итә.

2.4.2. Муниципаль хезмәт күрсәтү срогын туктату каралмаган.

2.4.3. Электрон документ формасында муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе булып торган документны гариза бирүчегә җибәрү муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе рәсмиләштерелгән һәм теркәлгән көнне гамәлгә ашырыла.

2.5. Муниципаль хезмәт күрсәтү, шулай ук муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләр күрсәтү өчен законнар һәм башка норматив-хокукый актлар нигезендә кирәкле һәм гариза бирүче тапшырырга тиешле документларның тулы исемлеге, гариза бирүче тарафыннан аларны кабул итү ысуллары, шул исәптән электрон формада, аларны тапшыру тәртибе

2.5.1. Муниципаль хезмәттән файдалану өчен гариза бирүче, мөрәҗәгать категориясенә һәм нигезенә бәйсез рәвештә, түбәндәге документларны тапшыра:

1) шәхесне раслаучы документ (Республика порталы аша мөрәҗәгать иткән очракта таләп ителми);

2) гариза бирүче вәкиленең вәкаләтләрен раслаучы документ, муниципаль хезмәт күрсәтүне сорап гариза бирүче вәкиле мөрәҗәгать иткән очракта (физик затларның законлы вәкилләре мөрәҗәгать иткән очракта таләп ителми: гаризада опека билгеләү турында карарның реквизитлары, Россия Федерациясе территориясендә бирелгән бала туу турында таныклык);

3) гариза:

- кәгазь документ формасында (әлеге Регламентка 8 нче, 9 нчы кушымталар);

- Республика порталы аша мөрәҗәгать иткәндә, Регламентның 2.5.5 пункты таләпләре нигезендә имзаланган электрон формада (тиешле мәгълүматларны гаризаның электрон формасына кертү юлы белән тутырыла) кабул ителә;

2.5.2. Гариза бирүче Регламентның 2.3.1. пунктының 1-3, 5 пунктчаларында күрсәтелгән муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен алу өчен мөрәҗәгать иткән очракта:

2.5.2.1. Гаризага теркәлә:

1) гариза бирүченең җир участогын гариза бирүче категориясе һәм әлеге Регламентның 4 нче кушымтасында бирелгән исемлек нигезендә сатулар үткәрмичә алу хокукын раслаучы документлар, орган тарафыннан ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек тәртибендә соратып алына торган документлардан тыш. Күрсәтелгән документлар органга җир участогын бирүне алдан килештерү турында гариза белән җибәрелгән һәм аны карау нәтиҗәләре буенча җир участогы бирүне алдан килештерү турында карар кабул ителгән очракта күрсәтелгән документларны бирү таләп ителми;

2) гариза бирүче чит ил юридик заты булган очракта, чит ил дәүләте законнары нигезендә юридик затны дәүләт теркәвенә алу турындагы документларның рус телендә расланган тәрҗемәсе;

3) бакчачылык яки яшелчәчелек коммерцияле булмаган ширкәт тарафыннан әзерләнгән мондый ширкәт әгъзаларының реестры, әгәр мондый ширкәткә түләүсез файдалануга җир участогы бирү турында гариза бирелгән булса.

2.5.2.2. Гаризада күрсәтелә:

1) гариза бирүченең фамилиясе, исеме һәм (булганда) атасының исеме, яшәү урыны, гариза бирүченең шәхесен таныклаучы документ реквизитлары (граждан өчен);

2) гариза бирүченең исеме һәм урнашу урыны (юридик зат өчен), шулай ук бердәм дәүләт юридик затлар реестрында юридик затны дәүләт теркәвенә алу турында язманың дәүләт теркәү номеры һәм салым түләүченең идентификация номеры, гариза бирүче чит ил юридик заты булган очраклардан тыш;

3) җир участогының кадастр номеры;

4) 39.3 статьясының 2 пунктында, 39.6 статьясының 2 пунктында, 39.9 статьясының 3 пунктында яки 39.10 статьясының 2 пунктында каралган нигезләр арасыннан җир участогын сатулар үткәрмичә бирү нигезе;

5) җир участогы бирү хокукының берничә төре мөмкин булса, гариза бирүче җир участогы алырга тели торган хокук төре;

6) җир участогы дәүләт яки муниципаль ихтыяҗлар өчен алына торган җир участогы урынына бирелгән очракта, җир участогын дәүләт яки муниципаль ихтыяҗлар өчен алу турында карар реквизитлары;

7) җир участогыннан файдалану максаты;

8) җир участогы күрсәтелгән документ һәм (яки) проектта каралган объектларны урнаштыру өчен бирелгән очракта, территориаль планлаштыру документын һәм (яки) территорияне планлаштыру проектын раслау турында карар реквизитлары;

9) сорала торган җир участогы барлыкка килгән яки аның чикләре әлеге карар нигезендә төгәлләштерелгән очракта, җир участогы бирүне алдан килештерү турында карар реквизитлары;

10) Россия Федерациясе Җир кодексының 39.3 статьясындагы 2 пунктының 7 пунктчасында каралган очракларда, җир участогын милеккә яки арендага бирү турындагы гаризада җир участогыннан даими (сроксыз) файдалану хокукын туктату турында хәбәр итеЛә һәм мондый җир участогын даими (сроксыз) файдалануга бирү турында карар реквизитлары күрсәтелә;

11) гариза бирүчегә хәбәр итү һәм муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен алу ысуллары.

2.5.3. Гариза бирүче Регламентның 2.3.1. пунктының 4 пунктчасында күрсәтелгән муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен сорап мөрәҗәгать иткән очракта гаризада күрсәтелә:

1) гариза бирүченең фамилиясе, исеме һәм (булганда) атасының исеме, яшәү урыны, гариза бирүченең шәхесен таныклаучы документ реквизитлары (граждан өчен);

2) гариза бирүченең исеме һәм урнашу урыны (юридик зат өчен), шулай ук бердәм дәүләт юридик затлар реестрында юридик затны дәүләт теркәвенә алу турында язманың дәүләт теркәү номеры һәм салым түләүченең идентификация номеры, гариза бирүче чит ил юридик заты булган очраклардан тыш;

3) җир участогының кадастр номеры;

4) җир участогын арендага бирү шартнамәсенә яки җир участогыннан түләүсез файдалану шартнамәсенә үзгәрешләр кертү өчен нигез;

6) җир участогын арендага бирү шартнамәсенә яки җир участогыннан түләүсез файдалану шартнамәсенә үзгәрешләр кертү өчен нигез булып торучы документ реквизитлары;

7) гариза бирүчегә хәбәр итү һәм муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен алу ысуллары.

2.5.4. Гариза һәм теркәлә торган документлар гариза бирүче тарафыннан түбәндәге ысулларның берсе белән тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин:

1) КФҮ аша кәгазьдә һәм регламентның 2.5.5 пункты таләпләренә туры килә торган электрон документлар рәвешендә;

2) Республика порталы аша электрон формада;

3) органга шәхсән яки кәгазьдә почта элемтәсе аша. Почта элемтәсе аша җибәргәндә гариза һәм аңа теркәлә торган документлар билгеләнгән тәртиптә раслана.

2.5.5. Республика порталы аша җибәргәндә гариза гариза бирүченең гади электрон имзасы белән имзалана.

Гади электрон имза алу өчен гариза бирүчегә ЕСИАда теркәлү (аутентификацияләү) процедурасын узарга, шулай ук хисап язмасын расларга кирәк.

Регламентның 2.5.1 пунктындагы 2 пунктчасында, 2.5.2. пунктында күрсәтелгән электрон документлар (документларның электрон үрнәкләре) мондый документларны төзүгә һәм имзалауга вәкаләтле затларның, шул исәптән нотариусларның көчәйтелгән квалификацияле имзасы белән раслана.

Гаризага теркәлә торган электрон документлар (документларның электрон рәвешләре), шул исәптән ышаныч кәгазьләре pdf, jpg, jpeg, png, tif, doc, docx, rtf форматларында 50 Мбайттан да артмаган күләмдә файллар рәвешендә җибәрелә.

Бирелгән электрон документларның (документларның электрон рәвешләренең) сыйфаты документ текстын тулы күләмдә укырга һәм документ реквизитларын танырга мөмкинлек бирергә тиеш.

2.5.6. Гариза бирүчедән таләп итү тыела:

1) муниципаль хезмәт күрсәтүгә бәйле барлыкка килә торган мөнәсәбәтләрне җайга сала торган норматив хокукый актларда тапшыру яки гамәлгә ашыру каралмаган документлар һәм мәгълүмат тапшыруны яки эшләрне гамәлгә ашыруны;

2) муниципаль хезмәттән файдалану өчен кирәкле һәм башка дәүләт органнарына, җирле үзидарә органнарына, оешмаларга мөрәҗәгать итүгә бәйле гамәлләрне, шул исәптән килешүләрне гамәлгә ашыру, 210-ФЗ номерлы Федераль законның 9 статьясының 1 өлешендә күрсәтелгән исемлеккә кертелгән хезмәтләрдән файдаланудан һәм мондый хезмәтләр (кирәкле һәм мәҗбүри хезмәтләр) күрсәтү нәтиҗәсендә бирелә торган документларны һәм мәгълүматны алудан тыш;

3) муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән яисә муниципаль хезмәт күрсәтүдән беренче тапкыр баш тартканда булмавы һәм (яки) дөрес булмавы күрсәтелмәгән документлар яки мәгълүмат тапшыруны, түбәндәге очраклардан тыш:

а) муниципаль хезмәт күрсәтү турында гаризаны беренче тапкыр биргәннән соң, муниципаль хезмәт күрсәтүгә кагылышлы норматив хокукый актларның таләпләре үзгәрү;

б) муниципаль хезмәт күрсәтү турында гаризада һәм муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән яисә муниципаль хезмәт күрсәтүдән беренче тапкыр баш тартканнан соң гариза бирүче тарафыннан тапшырылган һәм элек бирелгән документлар комплектына кертелмәгән документларда хаталар булу;

в) документларның гамәлдә булу срогы тәмамлану яки муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән яисә муниципаль хезмәт күрсәтүдән беренче тапкыр баш тартканнан соң мәгълүмат үзгәрү;

г) муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән яисә муниципаль хезмәт күрсәтүдән беренче тапкыр баш тартканда, Органның вазыйфаи затының, КФҮ хезмәткәренең хаталы яки хокукка каршы гамәленең (гамәл кылмавының) докуметлар белән расланган факты (билгеләре) ачыклану, муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән беренче тапкыр баш тартканда, бу хакта Орган Җитәкчесе имзасы белән язма рәвештә гариза бирүчегә хәбәр ителә, шулай ук тудырылган уңайсызлыклар өчен гафу үтенелә;

4) 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясындагы 1 өлешнең 7.2 пункты нигезендә элек электрон рәвешләре танықланган документларны һәм мәгълүматны кәгазьдә бирү, мондый документларга тамгалар кую яисә аларны алу дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүнең кирәкле шарты булып торган очраклардан һәм федераль законнарда билгеләнгән башка очраклардан тыш.

### 2.6. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен норматив хокукый актлар нигезендә кирәкле, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм дәүләт органнарының яки җирле үзидарә органнарының ведомство буйсынуындагы

оешмалар карамагындагы һәм гариза бирүче тапшырырга хокуклы документларның тулы исемлеге, шулай ук гариза бирүче тарафыннан аларны алу ысуллары, шул исәптән электрон формада, аларны бирү тәртибе; әлеге документлар алар карамагында булган дәүләт органы, җирле үзидарә органы яисә оешма

2.6.1. Ведомствоара хезмәттәшлек кысаларында алына:

1) юридик зат гариза биргән очракта Бердәм дәүләт юридик затлар реестрыннан өземтә – Федераль салым хезмәте;

2) шәхси эшмәкәр гариза биргән очракта Бердәм дәүләт шәхси эшмәкәрләр реестрыннан өземтә – Федераль салым хезмәте;

3) сорала торган җир участогына Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрыннан өземтә -Росреестр;

4) җир участогын арендалау шартнамәсе, әгәр җир участогын арендага бирү өчен арендатор мөрәҗәгать итсә – Орган;

5) территорияне межалау проекты-Орган;

6) территорияне планлаштыру буенча расланган проект-Орган;

7) бакчачылык яки яшелчәчелек ширкәтенә башлангыч җир участогын бирү турында документ, әгәр түләп милеккә алу буенча коммерцияле булмаган бакчачылык яки яшелчәчелек ширкәт әгъзасы мөрәҗәгать итсә яки бакчачылык яки яшелчәчелек ширкәте әгъзаларының гомуми җыелышы карары белән вәкаләтләнгән зат яки бакчачылык яки яшелчәчелек ширкәте әгъзасы арендага алу турында мөрәҗәгать итсә – Орган;

8) күчемсез милек объекты турында Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрыннан өземтә, әгәр бинадагы, корылмадагы бина, корылманың милекчесе түләп милеккә алу өчен мөрәҗәгать итсә яки аңа түләүсез файдалану хокукында бина, корылма бирелгән дини оешма түләүсез файдалануга бирүне сорап мөрәҗәгать итсә – Росреестр;

9) коммерцияле файдаланудагы наемга алынган йортны төзү һәм эксплуатацияләү максатларында территорияне үзләштерү турында шартнамә яки социаль файдаланудагы наемга алынган йортны төзү һәм эксплуатацияләү максатларында территорияне үзләштерү турында шартнамә, әгәр арендага бирү өчен аның белән территорияне үзләштерү турында шартнамә төзелгән зат мөрәҗәгать итсә - Орган;

10) территорияне комплекслы үстерү турында шартнамә, әгәр арендага бирү өчен аның белән территорияне комплекслы үстерү турында шартнамә төзелгән зат мөрәҗәгать итсә – Орган;

11) оборона һәм куркынычсызлык ихтыяҗлары өчен бирелгән һәм вакытлыча файдаланылмый торган җир участоклары исемлеге, әгәр авыл хуҗалыгы, аучылык хуҗалыгы, урман хуҗалыгы өчен түләүсез файдалануга участок сораучы зат мөрәҗәгать итсә – Орган;

12) сорала торган җир участогында урнашкан төзелеше тәмамланмаган объект (лар) турында Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрыннан өземтә, әгәр арендага бирү өчен тәмамланмаган төзелеш объектының милекчесе мөрәҗәгать итсә – Росреестр;

13) балыкчылык участогыннан файдалану шартнамәсе, әгәр арендага бирү өчен товар аквакультурасын (товар балыкчылыгын) гамәлгә ашыручы зат мөрәҗәгать итсә – Татарстан Республикасының биологик ресурслар буенча Дәүләт комитеты;

14) су биологик ресурсларын файдалануга бирү турында карар, әгәр арендага бирү өчен су биологик ресурсларын табу (тоту) хокукына ия зат мөрәҗәгать итсә – Татарстан Республикасының биологик ресурслар буенча Дәүләт комитеты;

15) балык тоту участогын бирү турында карар, әгәр арендага бирү өчен су биологик ресурсларын табу (тоту) хокукына ия зат мөрәҗәгать итсә – Татарстан Республикасының биологик ресурслар буенча Дәүләт комитеты;

16) су биологик ресурсларыннан файдалану шартнамәсе, әгәр арендага бирү өчен су биологик ресурсларын табу (тоту) хокукына ия зат мөрәҗәгать итсә – Татарстан Республикасының биологик ресурслар буенча Дәүләт комитеты;

17) Россия Федерациясе Хөкүмәте боерыгы, әгәр арендага бирү буенча социаль объектларны урнаштыру өчен участок сораучы зат мөрәҗәгать итсә – Орган;

18) Россия Федерациясе субъектының иң югары вазыйфаи заты боерыгы, әгәр әгәр арендага бирү буенча социаль объектларны урнаштыру өчен участок сораучы зат мөрәҗәгать итсә – Орган;

19) Россия Федерациясе Президенты Указы, әгәр зат арендага бирү өчен Россия Федерациясе Президенты Указы яисә күрсәтмәсе нигезендә мөрәҗәгать итсә – Орган;

20) Россия Федерациясе Президенты күрсәтмәсе, әгәр зат арендага бирү өчен Россия Федерациясе Президенты Указы яисә күрсәтмәсе нигезендә мөрәҗәгать итсә – Орган;

21) сорала торган җир участогын бирүне алдан килештерү турында карар, әгәр җир участогы бирүне алдан килештерү гамәлгә ашырылган булса – орган;

22) инвалидлык билгеләү фактын раслаучы мәгълүматлар – Россия Федерациясе Пенсия фонды;

23) адресация объектына бирелгән адрес турында мәгълүматлар – федераль мәгълүмати адрес системасы;

24) урман участокларының чикләре турында мәгълүматлар – Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы;

25) су объектларының чикләре турында мәгълүматлар – Татарстан Республикасы Экология һәм табигый байлыклар министрлыгы;

26) сорала торган җир участогындагы төзелмәләр булу турында мәгълүматлар – электрон хуҗалык кенәгәсе;

27) җир участогын бирү өчен чикләүләр булу турында яки булмау турында (шул исәптән территориаль зона, кызыл линияләрнең чикләре, территориядән файдалануның махсус шартлары булган зоналар булу, рөхсәт ителгән төзелешнең чик параметрлары турында) бәяләмә – муниципаль район (шәһәр округы) Башкарма комитетының архитектура һәм шәһәр төзелеше идарәсе (МКУ, бүлек);

28) җир участогын беренче чиратта яки чираттан тыш бирү хокукын гамәлгә ашыручы затлар реестрыннан мәгълүматлар – Орган;

29) гариза законлы вәкил тарафыннан бирелгән очракта, гариза бирүченең законлы вәкиленең вәкаләтләрен раслый торган документ (Россия Федерациясе Гражданнар хәле актларын теркәү органнары тарафыннан бирелгән туу турында таныклык яки Россия Федерациясе законнары нигезендә опека һәм попечительлек органнары тарафыннан бирелгән документ өлешендә) – Бердәм дәүләт гражданнар хәле актларын теркәү реестры яисә социаль тәэминатның Бердәм дәүләт мәгълүмат системасы;

30) ышаныч язуы бирү факты һәм аның эчтәлеге турында мәгълүматлар – нотариатның бердәм мәгълүмат системасы.

2.6.2. Орган карамагында җир участогының территориядән файдалануның махсус шартлары булган зоналарда урнашуы турында мәгълүмат булган очракта, җир участогына бару гамәлгә ашырыла, аның нәтиҗәләре буенча тикшерү (фотофиксация белән җир участогын карау) материаллары төзелә.

2.6.3. Гариза бирүче гариза биргәндә Регламентның 2.6.1 пунктының 1-9 пунктчаларында күрсәтелгән документларны (мәгълүматларны), мондый документларны төзүгә һәм имзалауга вәкаләтле затларның көчәйтелгән квалификацияле имзасы белән таныкланган электрон документлар формасында бирергә хокуклы.

2.6.4. Регламентның 2.6.1 пунктында күрсәтелгән документлар һәм мәгълүматлар дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары, оешмалар

тарафыннан тапшырылмау (вакытында тапшырылмау) муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту өчен нигез була алмый.

2.6.5. Регламентның 2.6.1 пунктында күрсәтелгән органнарның сорала торган һәм алар карамагында булган документларны яки мәгълүматларны тапшырмаган (үз вакытында тапшырмаган) вазыйфаи заты һәм (яки) хезмәткәре Россия Федерациясе законнары нигезендә административ, дисциплинар яки башка җаваплылыкка тартылырга тиеш.

2.6.6. Гариза бирүчедән дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм дәүләт органнарының яки җирле үзидарә органнарының ведомство буйсынуындагы оешмалар карамагында булган, шул исәптән муниципаль хезмәт күрсәтү өчен гариза бирүче тарафыннан түләү кертүне раслаучы документлар, мәгълүматлар таләп итү тыела.

Гариза бирүче тарафыннан дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм дәүләт органнарының яки җирле үзидарә органнарының ведомство буйсынуындагы оешмалар карамагында булган мәгълүматларны үз эченә алган документларны тапшылмау гариза бирүчегә муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту өчен нигез булып тормый.

### 2.7. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту (асылда карап тикшермичә документларны кире кайтару) өчен нигезләрнең тулы исемлеге

2.7.1. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләр булып тора:

1) Республика порталындагы гариза формасында мәҗбүри кырларны дөрес тутырмау (тутырылмау, Регламентта билгеләнгән таләпләргә туры килми торган дөрес түгел, тулы булмаган яисә хаталы);

2) документ текстын тулы күләмдә укырга һәм (яки) документ реквизитларын танырга мөмкинлек бирми торган электрон документлар (документларның электрон рәвешләрен) тапшыру;

3) электрон имзаны тикшерү ачкычының квалификацияле сертификаты хуҗасының мәгълүматлары гариза бирүченең Республика порталы аша электрон формада бирелгән гаризасында күрсәтелгән мәгълүматларга туры килми;

4) Регламент белән каралган, муниципаль хезмәт күрсәтү өчен мәҗбүри булган документларның тулы комплекты бирелмәгән;

5) документларда мәгълүматны һәм белешмәләрне тулы күләмдә файдаланырга, текстны укырга һәм (яки) документ реквизитларын танырга мөмкинлек бирми торган бозулар бар;

6) гариза һәм башка документларның электрон формада документларны тапшыруга вәкаләтләнмәгән зат тарафыннан бирелүе;

7) документларда закон белән билгеләнгән тәртиптә расланмаган төзәтүләр бар;

8) муниципаль хезмәт күрсәтүне сорап мөрәҗәгать иткән вакытка документлар үз көчен югалткан.

2.7.2. Муниципаль хезмәттән файдалану өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләр исемлеге тулы булып тора.

2.7.3. Гаризаны һәм муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту турындагы карар гариза бирүчене кабул итү вакытында да, гаризаны теркәгән көннән башлап 9 эш көненнән артмаган срокта, Органның җаваплы вазыйфаи заты тарафыннан ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлектән файдаланып, муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны (мәгълүматларны) алганнан соң да кабул ителергә мөмкин.

2.7.4. Муниципаль хезмәттән файдалану өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту турындагы карар, баш тарту сәбәпләрен күрсәтеп, әлеге Регламентка 10 нчы кушымтада билгеләнгән форма нигезендә рәсмиләштерелә, Органның (Орган тарафыннан) вәкаләтле вазыйфаи заты тарафыннан билгеләнгән тәртиптә көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзалана һәм Республика порталының шәхси кабинетына гариза бирүчегә һәм (яки) муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту турында карар кабул ителгән көнне КФҮгә җибәрелә.

2.7.5. Гариза һәм муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документлар, Бердәм порталда, Республика порталында бастырып чыгарылган муниципаль хезмәт күрсәтү сроклары һәм тәртибе турындагы мәгълүмат нигезендә тапшырылган очракта, гаризаны һәм муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле башка документларны кабул итүдән баш тарту тыела.

## 2.8. Муниципаль хезмәт күрсәтүне туктату яки баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге

2.8.1. Муниципаль хезмәт күрсәтүне туктату өчен нигезләр юк.

2.8.2. Муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр исемлеге:

2.8.2.1. Барлыкка килергә тиешле җир участогы Россия Федерациясе Җир кодексының 39.16 статьясында күрсәтелгән нигезләр буенча гариза бирүчегә бирелә алмый, атап әйткәндә:

1) җир участогы бирү турындагы гариза белән җир законнары нигезендә җир участогын сатулар үткәрмичә алу хокукына ия булмаган зат мөрәҗәгать иткән;

2) җир участогы бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир участогы даими (сроксыз) файдалану, түләүсез файдалану, гомерлек мираска ия булу яки аренда хокукында бирелгән, җир участогы бирү турында гариза белән әлеге хокукларга ия булучы мөрәҗәгать иткән яисә җир участогы бирү турында гариза Россия Федерациясе Җир кодексының 39.10 статьясындагы 2 пунктының 10 пунктчасы нигезендә бирелгән очраклардан тыш;

3) җир участогы бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир участогы коммерцияле булмаган бакчачылык яки яшелчәчелек ширкәтләренә бирелгән җир участогын бүлү нәтиҗәсендә барлыкка килгән, мондый гариза белән әлеге ширкәт әгъзасы (әгәр мондый җир участогы җимеш бакчасы яки яшелчә бакчасы булса) яисә гражданнар тарафыннан үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык яки яшелчәчелек алып бару территориясе чикләрендә урнашкан җир участоклары милекчеләре мөрәҗәгать итү очракларыннан тыш;

4) җир участогы бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир участогында гражданнарга яисә юридик затларга караган бина, корылма, тәмамланмаган төзелеш объекты урнашкан, аларны урнаштыру сервитут, гавами сервитут нигезендә рөхсәт ителә торган корылмалар (шул исәптән төзелеше тәмамланмаган корылмалар) яки Россия Федерациясе Җир кодексының 39.36 статьясы нигезендә урнашкан объектлар урнашкан яисә җир участогы бирү турында гариза белән әлеге бина, корылма, алардагы бина, әлеге тәмамланмаган төзелеш объектының милекчесе мөрәҗәгать иткән очраклардан тыш, шулай ук анда урнашкан биналар, корылмалар, тәмамланмаган төзелеш объектына карата рөхсәтсез төзелгән корылманы сүтү турында карар кабул ителгән яисә билгеләнгән таләпләр нигезендә рөхсәтсез корылманы сүтү яки күрсәтелгән карарлар белән билгеләнгән срокларда аны тәртипкә китерү буенча Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 55.32 статьясындагы 11 өлештә билгеләнгән йөкләмәләр үтәлмәгән җир участогын бирү турында гариза бирелгән очраклардан тыш;

5) җир участогы бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир участогында дәүләт яки муниципаль милектә булган бина, корылма, тәмамланмаган төзелеш объекты урнашкан, җир участогында аларны урнаштыру сервитут, гавами сервитут нигезендә рөхсәт ителгән корылмалар (шул исәптән төзелеше тәмамланмаган корылмалар) яисә Россия Федерациясе Җир кодексының 39.36 статьясы нигезендә урнашкан объектлар урнашкан яисә җир участогы бирү турында гариза белән әлеге биналар, корылмалар, алардагы бүлмәләр, әлеге тәмамланмаган төзелеш объектының хуҗасы мөрәҗәгать иткән очраклардан тыш;

6) җир участогы бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир участогы әйләнештән алынган яисә әйләнештә чикләнгән булып тора һәм аны бирү җир участогы бирү турындагы гаризада күрсәтелгән хокук буенча рөхсәт ителми;

7) җир участогы бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир участогы дәүләт яисә муниципаль ихтыяҗлар өчен резервланган җир булып тора, әгәр мөрәҗәгать итүче җир участогын милеккә, даими (сроксыз) файдалануга яисә җир участогын арендага бирү турындагы гариза белән, җир участогын резервлау максатларында җир участогы бирү турындагы карарның гамәлдә булу срогыннан артык вакытка түләүсез файдалануга бирү турында гариза белән мөрәҗәгать иткән очракта, җир участогын резервлау максатларында бирү очрагыннан тыш;

8) җир участогы бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир участогы аңа карата башка зат белән төзелә торган территорияне үстерү турында шартнамә төзелгән территория чикләрендә урнашкан, җир участогы бирү турында гариза белән шул җир участогында урнашкан бина, корылмалар, алардагы бүлмәләрнең, тәмамланмаган төзелеш объектының милекчесе яки җир участогының хуҗасы мөрәҗәгать иткән очраклардан тыш;

9) җир участогы бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир участогы аңа карата башка зат белән территорияне комплекслы үстерү турында шартнамә төзелгән җир участогы чикләрендә урнашкан яки җир участогы башка зат белән территорияне комплекслы үстерү турында шартнамә төзелгән җир участогыннән ясалган, мондый җир участогы федераль әһәмияттәге объектларны, региональ әһәмияттәге объектларны яки җирле әһәмияттәге объектларны урнаштыру өчен билгеләнгән һәм мондый җир участогын бирү турында гариза белән күрсәтелгән объектларны төзүгә вәкаләтле зат мөрәҗәгать иткән очраклардан тыш;

10) җир участогы бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир участогы аңа карата территорияне комплекслы үстерү турында шартнамә төзелгән җир участогыннән төзелгән һәм территорияне планлаштыру буенча расланган документ нигезендә федераль әһәмияткә ия объектларны, региональ әһәмияткә ия объектларны яки җирле әһәмияткә ия объектларны урнаштыру өчен билгеләнгән, җир участогын арендага бирү турындагы гариза белән әлеге затның әлеге объектларны төзү буенча йөкләмәсен күздә тотучы территорияне комплекслы үстерү турында шартнамә төзелгән зат мөрәҗәгать иткән очраклардан тыш;

11) җир участогын бирү турында гаризада күрсәтелгән җир участогы, аны үткәрү турында белдерү Россия Федерациясе Җир кодексының 39.11 статьясындагы 19 *пункты ни*гезендә урнаштырылган аукцион предметы булып тора;

12) аны бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир участогына карата, мондый җир участогы Россия Федерациясе Җир кодексының 39.11 статьясындагы 4 пунктның 4 пунктчасы нигезендә ясалган һәм вәкаләтле орган тарафыннан, Россия Федерациясе Җир кодексының 39.11 статьясындагы 8 пунктында каралган нигезләр буенча, әлеге аукционны үткәрүдән баш тарту турында карар кабул ителмәгән булса, аны сату буенча Россия Федерациясе Җир кодексының 39.11 статьясындагы 4 пунктының 6 пунктчасында каралган аукцион яки арендага алуга шартнамә төзү хокукына аукцион үткәрү турында гариза кергән;

13) аны бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир участогына карата РФ Җир кодексының 39.18 статьясындагы 1 пунктының 1 пунктчасы нигезендә шәхси торак төзелеше, шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару, бакчачылык яки крестьян (фермер) хуҗалыгы эшчәнлеге өчен җир участогы бирү турында белдерү басылып чыккан һәм урнаштырылган;

14) җир участогыннан рөхсәт ителгән файдалану мондый җир участогыннан җир участогы бирү турында гаризада күрсәтелгән файдалану максатларына туры килми, линия объектын территорияне планлаштыруның расланган проекты нигезендә урнаштыру очракларыннан тыш;

14.1) сорала торган җир участогы тулысынча территориядән файдалануның махсус шартлары булган зона чикләрендә урнашкан, анда җир участокларыннан файдалануның билгеләнгән чикләүләре буенча әлеге җир участогыннан җир участогы бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир участогыннан файдалану максатлары нигезендә файдаланырга рөхсәт ителми;

15) сорала торган җир участогы Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән тәртиптә расланган оборона һәм куркынычсызлык ихтыяҗлары өчен бирелгән һәм күрсәтелгән ихтыяҗлар өчен вакытлыча кулланылмый торган җир участоклары исемлегенә кертелмәгән, әгәр җир участогы бирү турында гариза РФ Җир Кодексының 39.10 статьясындагы 2 пунктының 10 пунктчасы нигезендә бирелгән булса;

16) коммерцияле булмаган бакчачылык яки бакчачылык ширкәтенә җир участогы бирү турында гаризада күрсәтелгән җир участогының мәйданы Россия Федерациясе Җир кодексының 39.10 статьясындагы 6 пунктында билгеләнгән чик күләменнән артып китә;

17) җир участогы бирү турында гаризада күрсәтелгән җир участогы территориаль планлаштыруның расланган документлары һәм (яки) территорияне планлаштыру буенча документлар нигезендә федераль әһәмияттәге объектларны, региональ әһәмияттәге объектларны яки җирле әһәмияттәге объектларны урнаштыру өчен билгеләнгән һәм җир участогы бирү турында гариза белән әлеге объектлар төзүгә вәкаләтле булмаган зат мөрәҗәгать иткән;

18) җир участогы бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир участогы Россия Федерациясе дәүләт программасы, Россия Федерациясе субъектының дәүләт программасы нигезендә бина, корылмалар урнаштыру өчен билгеләнгән һәм җир участогы бирү турында гариза белән әлеге биналар, корылмаларны төзүгә вәкаләтле булмаган зат мөрәҗәгать иткән;

19) белдерелгән хокуклар буенча җир участогы бирү рөхсәт ителми;

20) аны бирү турында гаризада күрсәтелгән җир участогына карата рөхсәт ителгән файдалану төре билгеләнмәгән;

21) җир участогы бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир участогы җирләрнең билгеле бер категориясенә кертелмәгән;

22) аны бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир участогына карата аны бирүне алдан килештерү турында карар кабул ителгән һәм аның гамәлдә булу срогы чыкмаган һәм җир участогы бирү турындагы гариза белән бу карарда күрсәтелмәгән башка зат мөрәҗәгать иткән;

23) җир участогы бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир участогы дәүләт яки муниципаль ихтыяҗлар өчен тартып алынган һәм гаризада күрсәтелгән җир участогын бирү максаты мондый җир участогын тартып алу максатларына туры килми, мондый җир участогында урнашкан күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиешле дип тануга бәйле рәвештә дәүләт яки муниципаль ихтыяҗлар өчен алынган җир участокларыннан тыш;

24) аны бирү турында гаризада күрсәтелгән җир участогының чикләренә «Күчемсез милекне дәүләт теркәве турында» 2015 елның 13 июлендәге 218-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә төгәллек кертелергә тиеш;

25) аны бирү турында гаризада күрсәтелгән җир участогының мәйданы алар нигезендә мондый җир участогы төзелгән җир участогының урнашу схемасы, территорияне межалау проекты яисә урман участокларының проект документларында күрсәтелгән мәйданыннан ун проценттан артып китә;

26) «Россия Федерациясендә кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү турында» 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы Федераль законның 18 статьясындагы 4 өлешендә каралган дәүләт милке исемлегенә яисә муниципаль мөлкәт исемлегенә кертелгән җир участогы бирү турындагы гариза белән кече һәм урта эшмәкәрлек субъекты булмаган зат яисә күрсәтелгән Федераль законның 14 статьясындагы 3 өлеше нигезендә ярдәм күрсәтелә алмый торган зат мөрәҗәгать иткән.

2.8.2.2. Гражданнарга торак пункт, бакчачылык чикләрендә индивидуаль торак төзелеше, шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен, гражданнарга һәм крестьян (фермер) хуҗалыкларына крестьян (фермер) хуҗалыгы тарафыннан эшчәнлеген алып бару өчен җир участогы бирү турында хәбәр басылып чыккан көннән башлап утыз көн эчендә башка гражданнарның аукционда катнашырга теләве турында гаризалары керү.

2.8.2.3. Гариза бирүченең шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен бер үк вакытта милек хокукында һәм (яки) башка хокукта булган җир участокларының гомуми мәйданы «Шәхси ярдәмче хуҗалык турында» 2003 елның 7 июлендәге 112-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә билгеләнгән максималь күләмнән артып китә.

2.8.2.4. Җир участогы коммерцияле булмаган бакчачылык яки яшелчәчелек берләшмә чикләрендә урнашу һәм территорияне оештыру һәм төзү проекты яки әлеге берләшмә территориясен межалау проекты булмау.

2.8.2.5. Җир участогы сорала торган максат, шәһәр төзелеше регламентында шәһәр төзелешен зоналаштыру документларында тиешле территориаль зона өчен билгеләнгән рөхсәт ителгән файдалануның төп төренә туры килми.

2.8.2.6. Сорала торган җир участогыннан файдалану максаты территорияне планлаштыру проектының территориаль зоналарында, территорияне межалау проектында билгеләнгән рөхсәт ителгән файдалануның төп төрләренә туры килмәү (шул исәптән җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре территориаль зоналарында билгеләнгән рөхсәт ителгән файдалану төрләрендә икенче төрле укылганда).

2.8.2.7. Индивидуаль торак төзелеше өчен рөхсәт ителгән файдалану төре булган сорала торган җир участогында торак булмаган билгеләнештәге бина урнашкан.

2.8.2.8. Коммерцияле булмаган бакчачылык ширкәте чикләреннән читтә урнашкан сорала торган җир участогының гомуми төзелеш (индивидуаль торак йорт, торак дача йорты, бакча йорты) мәйданы төзелешнең территориаль планлаштыру һәм шәһәр төзелешен зоналаштыру документларында билгеләнгән чик параметрларыннан артып китә.

2.8.2.9. Чит ил гражданы, чит ил юридик заты, гражданлыгы булмаган затлар, шулай ук устав (склад) капиталында чит ил гражданнары, чит ил юридик затлары, гражданлыгы булмаган затлар өлеше 50 проценттан артык тәшкил иткән юридик затның авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрдән җир участоклары алу өчен мөрәҗәгать итүе.

2.8.3. Муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр исемлеге тулы булып тора.

2.8.4. Баш тарту сәбәпләрен күрсәтеп, муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту турында карар әлеге Регламентка 2 нче кушымтада каралган форма нигезендә рәсмиләштерелә, билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетның (Органның) вәкаләтле вазыйфаи заты

тарафыннан көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзалана һәм гариза бирүчегә муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту турында карар кабул ителгән көнне Республика порталының шәхси кабинетына гариза бирүчегә һәм (яки) КФҮгә җибәрелә.

2.8.5. Муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза Бердәм порталда, Республика порталында бастырып чыгарылган муниципаль хезмәт күрсәтү сроклары һәм тәртибе турындагы мәгълүмат нигезендә бирелгән очракта, муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту тыела.

2.9. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен алына торган дәүләт пошлинасын яки башка түләүне алу тәртибе, күләме һәм нигезләре

Муниципаль хезмәт түләүсез нигездә күрсәтелә.

2.10. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләр исемлеге, шул исәптән муниципаль хезмәтләр күрсәтүдә катнашучы оешмалар тарафыннан бирелә торган документ (документлар) турында мәгълүматлар

Кирәкле һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми.

2.11. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләр күрсәтүгә түләү алу тәртибе, күләме һәм нигезләре, мондый түләү күләмен исәпләү методикасы турында мәгълүматны да кертеп

Кирәкле һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми.

2.12. Муниципаль хезмәт, муниципаль хезмәт күрсәтүдә катнашучы оешма тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтне күрсәтү турында запрос биргәндә һәм мондый хезмәтләрне күрсәтү нәтиҗәсен алганда чиратта көтүнең максималь срогы

2.12.1. Муниципаль хезмәттән файдалануга гариза биргәндә көтү вакыты – 15 минуттан артык түгел.

2.12.2. Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен алганда чиратта көтүнең максималь срогы 15 минуттан артырга тиеш түгел.

2.13. Гариза бирүченең муниципаль хезмәт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүдә катнашучы оешма тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтне күрсәтү турында запросын теркәү срогы һәм тәртибе, шул исәптән электрон формада

2.13.1. Гариза биргән көнне КФҮгә шәхсән мөрәҗәгать иткәндә, гариза бирүчегә гаризаның җибәрелүен раслаучы теркәү номеры һәм гариза бирү датасы белән КФҮ АМСтан өземтә бирелә.

2.13.2. Гаризаны Республика порталы аша җибәргәндә, гариза бирүче гариза биргән көнне Республика порталының шәхси кабинетында һәм электрон почта аша, теркәү номеры һәм гариза бирү датасы күрсәтелгән, гариза җибәрелүне раслаучы белдерү кәгазе ала.

2.13.3. Органга шәхсән мөрәҗәгать иткәндә вәкаләтле органның вазыйфаи заты тарафыннан гариза бирелгән көнне гариза бирүчегә дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен билгеләнгән автоматлаштырылган мәгълүмат системасыннан теркәү номеры, гариза бирү датасы һәм тапшырылган документлар исемлеге белән расписка бирелә.

2.14. Муниципаль хезмәт күрсәтелә торган биналарга, көтү залына, муниципаль хезмәт күрсәтү турында запросларны тутыру урыннарына, аларны тутыру үрнәкләре һәм һәр муниципаль хезмәтне күрсәтү өчен кирәкле документлар исемлеге булган мәгълүмат стендларына, мондый хезмәтне күрсәтү тәртибе турында визуаль, текстлы һәм мультимедиа мәгълүмат урнаштыруга һәм рәсмиләштерүгә, шул исәптән инвалидларны социаль яклау турында федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә, күрсәтелгән объектларның инвалидлар өчен уңайлылыгын тәэмин итүгә таләпләр

2.14.1. Муниципаль хезмәт күрсәтү янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы белән җиһазландырылган биналарда һәм бүлмәләрдә гамәлгә ашырыла.

Гариза бирүчеләрне кабул итү урыннары документлар рәсмиләштерү өчен кирәкле мебель, мәгълүмат стендлары белән җиһазландырыла.

Инвалидларның муниципаль хезмәт күрсәтү урынына тоткарлыксыз керү мөмкинлеге тәэмин ителә (бинага уңайлы керү-чыгу һәм алар чикләрендә хәрәкәт итү).

Муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибе турындагы визуаль, текстлы һәм мультимедиа мәгълүмат гариза бирүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул исәптән инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен истә тотып урнаштырыла.

2.14.2. Инвалидларны социаль яклау турында Россия Федерациясе законнары нигезендә, муниципаль хезмәт күрсәтү урынына тоткарлыксыз керү максатларында тәэмин ителә:

1) күрү һәм мөстәкыйль хәрәкәт итү функциясе бозылган инвалидларны озатып йөрү һәм аларга ярдәм күрсәтү;

2) транспорт чарасына утыру һәм аннан төшү, шул исәптән кресло-коляскадан файдаланып;

3) аларның яшәеш мөмкинлекләре чикле булуны исәпкә алып, инвалидларның хезмәтләрдән тоткарлыксыз файдалануын тәэмин итү өчен кирәкле җиһазларны һәм мәгълүмат йөрткечләрне тиешенчә урнаштыру;

4) ишетә һәм күрә торган мәгълүматны, шулай ук язуларны, билгеләрне һәм башка текстлы һәм график мәгълүматны рельефлы-нокталы Брайль шрифтында башкарылган билгеләр белән кабатлау;

5) сурдотәрҗемәчене һәм тифлосурдотәрҗемәчене кертү;

6) Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының «Юл күрсәтүче этне махсус укытуны раслый торган документ формасын һәм аны бирү тәртибен раслау турында» 2015 елның 22 июнендәге 386н боерыгы белән билгеләнгән форма буенча һәм тәртиптә бирелә һәм махсус өйрәтелгән булуын раслый торган документы булганда, юл күрсәтүче этне кертү;

2.14.3. Инвалидлар өчен муниципаль хезмәт күрсәтү гамәлгә ашырыла торган объектларга керү һәм Регламентның 2.14.2 пунктының 1-4 пунктларында күрсәтелгән муниципаль хезмәт күрсәтүдә кулланыла торган чаралардан файдалануны тәэмин итү өлешендә таләпләр 2016 елның 1 июленнән соң файдалануга тапшырылган яки модернизацияләнгән, реконструкцияләнгән объектларга һәм чараларга карата кулланыла.

2.15. Муниципаль хезмәтнең һәркем файдалана алырлык булу һәм сыйфат күрсәткечләре, шул исәптән гариза бирүченең муниципаль хезмәт күрсәткәндә вазыйфаи затлар белән үзара эшчәнлеге саны һәм аларның дәвамлылыгы, муниципаль хезмәт күрсәтү барышы турында

мәгълүмат алу мөмкинлеге, шул исәптән мәгълүмат-коммуникация технологияләренән файдаланып, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча күпфункцияле үзәктә (шул исәптән тулы күләмдә), гариза бирүченең сайлавы буенча (экстерриториаль принцип), җирле үзидарә органы башкарма-боеру органының теләсә кайсы территориаль бүлекчәсендә, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча күпфункцияле үзәкләрдә 210-ФЗ номерлы Федераль законның 15.1 статьясында каралган берничә дәүләт һәм (яки) муниципаль хезмәт күрсәтү турында запрос (комплекслы запрос) ярдәмендә муниципаль хезмәттән файдалану мөмкинлеге яисә мөмкин булмау

2.15.1. Муниципаль хезмәт күрсәтүнең һәркем файдалана алырлык булу күрсәткечләре булып тора:

документларны кабул итү һәм бирү башкарыла торган бинаның җәмәгать транспортыннан һәркем файдалана алырлык зонада урнашуы;

кирәкле сандагы белгечләр, шулай ук гариза бирүчеләрдән документлар кабул итүне гамәлгә ашыра торган бүлмәләр булу;

мәгълүмат стендларында, муниципаль районның рәсми сайтында, Бердәм порталда, Республика порталында муниципаль хезмәт күрсәтү ысуллары, тәртибе һәм сроклары турында тулы мәгълүмат булу;

инвалидларга хезмәтләрдән башка затлар белән бертигез дәрәҗәдә файдалануга комачаулый торган каршылыкларны җиңеп чыгуда ярдәм күрсәтү.

2.15.2. Муниципаль хезмәт күрсәтүнең сыйфат күрсәткечләре булып тора:

1) документларны кабул итү һәм карап тикшерү срокларын үтәү;

2) муниципаль хезмәт нәтиҗәсен алу срогын үтәү;

3) Башкарма комитет хезмәткәрләре тарафыннан Регламентны бозуга нигезле шикаятьләр булмау;

4) гариза бирүченең вазыйфаи затлар белән үзара хезмәттәшлеге саны (консультацияләрне исәпкә алмыйча):

муниципаль хезмәт күрсәткәндә гариза бирүченең КФҮ хезмәткәрләре белән хезмәттәшлеге барлык кирәкле документлар белән гариза биргәндә бер тапкыр гамәлгә ашырыла;

КФҮдә муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен электрон документның кәгазь нөсхәсе формасында алу кирәк булган очракта бер тапкыр.

Муниципаль хезмәт күрсәткәндә, гариза бирүченең вазыйфаи затлар белән бер хезмәттәшлек дәвамлылыгы 15 минуттан артмый.

Гариза бирүче күчмә радиотелефон элемтәсе җайланмалары ярдәмендә, Бердәм порталдан, Республика порталыннан, терминал җайланмаларыннан файдаланып, муниципаль хезмәт күрсәтү сыйфатын бәяләргә хокуклы.

2.15.3. Муниципаль хезмәт күрсәтү барышы турында мәгълүмат гариза бирүче тарафыннан Бердәм порталда яки Республика порталында, КФҮдә алынырга мөмкин.

2.15.4. Муниципаль хезмәт күрсәтү экстерриториаль принцип буенча, яшәү урынына яки фактта яшәү (тору) урынына бәйсез рәвештә, гариза бирүченең сайлавы буенча теләсә кайсы КФҮдә гамәлгә ашырыла.

Регламентның 2.3.3 пунктының беренче абзацы нигезендә нәтиҗә бирү муниципаль районның гариза бирүче сайлап алган КФҮ бүлегендә (читтәге эш урынында) яисә сорала торган җир участогы урнашкан шәһәр округының КФҮ бүлегендә гамәлгә ашырыла.

Гариза бирүче муниципаль хезмәттән комплекслы запрос составында файдаланырга хокуклы.

## 2.16. Башка, шул исәптән экстерриториаль принцип буенча муниципаль хезмәт күрсәтү үзенчәлекләрен (әгәр муниципаль хезмәт экстерриториаль принцип буенча күрсәтелсә) һәм муниципаль хезмәтне электрон формада күрсәтү үзенчәлекләрен исәпкә алучы таләпләр

2.16.1. Муниципаль хезмәт электрон формада күрсәтелгәндә гариза бирүче хокуклы:

1) Бердәм порталда яки Республика порталында урнаштырылган муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибе һәм сроклары турында мәгълүмат алырга;

2) Республика порталыннан файдаланып, муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза һәм муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле башка документларны, шул исәптән 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясындагы 1 өлешнең 7.2 пункты нигезендә элек электрон рәвешләре танылканган документларны һәм мәгълүматны бирергә;

3) электрон формада бирелгән муниципаль хезмәт күрсәтү турындагы гаризаларны үтәү барышы турында мәгълүматлар алырга;

4) Республика порталы аша муниципаль хезмәт күрсәтү сыйфатын бәяләүне гамәлгә ашырырга;

5) муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен электрон документ формасында алырга;

6) Органның, шулай ук аның вазыйфаи затларының, муниципаль хезмәткәрләренең карарына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына), Республика порталы, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәткәндә дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче органнар, аларның вазыйфаи затлары, дәүләт һәм муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан башкарылган карарларга һәм гамәлләргә (гамәл кылмауга) судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү процессын тәэмин итә торган федераль дәүләт мәгълүмат системасы порталы аша шикаять бирергә.

2.16.2. Гаризаны формалаштыру, гаризаны нинди дә булса башка формада өстәмә рәвештә бирмичә, Республика порталында гаризаның электрон формасын тутыру юлы белән гамәлгә ашырыла.

2.16.3. Гаризаны Республика порталында формалаштырганда тәэмин ителә:

1) хезмәт күрсәтү өчен кирәкле гаризаны һәм башка документларны күчереп алу һәм саклау мөмкинлеге;

2) берничә гариза бирүче тарафыннан уртак гариза җибәрүне күздә тоткан хезмәтләр өчен мөрәҗәгать иткәндә, берничә гариза бирүченең гаризаның бер электрон формасын тутыру мөмкинлеге;

3) гаризаның электрон формасы күчермәсен кәгазьдә бастыру мөмкинлеге;

4) файдаланучының теләге буенча гаризаның электрон формасына теләсә кайсы вакытта кертелгән зурлыкларны саклап калу, шул исәптән кертүдә хаталар барлыкка килгәндә һәм гаризаның электрон формасына зурлыкларны кабат кертү өчен кире алганда;

5) Бердәм идентификацияләү һәм аутентификацияләү системасында булмаган мәгълүматларга кагылышлы өлешендә, гариза бирүче тарафыннан гаризаның электрон формасы кырларын, ЕСИАда урнашкан мәгълүматларны һәм Бердәм порталда, Республика порталында басылып чыккан мәгълүматларны файдаланып кертә башлаганчы тутыру;

6) элек кертелгән мәгълүматны югалтмыйча, гаризаның электрон формасын тутыруның теләсә кайсы этабына кире кайту мөмкинлеге;

7) гариза бирүченең Республика порталында аның тарафыннан элек бирелгән гаризаларына кимендә бер ел дәвамында, шулай ук өлешчә формалаштырылган гаризаларга - кимендә 3 ай дәвамында керә алу мөмкинлеге.

2.16.4. Гариза бирүчеләрнең КФҮгә кабул итүгә язылуы (алга таба – язылу) Республика порталы, КФҮнең контакт-үзәге телефоны аша гамәлгә ашырыла.

Гариза бирүчегә, күпфункцияле үзәктә билгеләнгән кабул итү графигы чикләрендә, кабул итү өчен теләсә кайсы буш датага һәм вакытка язылу мөмкинлеге бирелә.

Билгеле бер датага язылу әлеге датага кадәр бер тәүлек алдан тәмамлана.

Республика порталы аша алдан язылуны гамәлгә ашыру өчен, гариза бирүчегә системада сорала торган мәгълүматларны күрсәтергә кирәк, шул исәптән:

фамилиясе, исеме, атасының исеме (булганда);

телефон номеры;

электрон почта адресы (теләге буенча);

кабул итүне теләгән көн һәм вакыт.

Алдан язылу вакытында гариза бирүче хәбәр иткән мәгълүматлар шәхси кабул итү вакытында гариза бирүче тарафыннан бирелгән документларга туры килмәгән очракта, алдан язылу гамәлдән чыгарыла. Алдан язылуны гамәлгә ашырганда, гариза бирүчегә раслау талоны чыгартып алу мөмкинлеге бирелә. Гариза бирүче электрон почта адресын хәбәр иткән очракта, күрсәтелгән адреска шулай ук кабул итү датасын, вакытын һәм урынын күрсәтеп, алдан язылуны раслау турында мәгълүмат җибәрелә.

Алдан язылуны гамәлгә ашырганда гариза бирүчегә, кабул итүнең билгеләнгән вакытыннан 15 минут узгач, ул килмәгән очракта, алдан язылу гамәлдән чыгарылу турында мәҗбүри рәвештә хәбәр ителә.

Гариза бирүче теләсә кайсы вакытта алдан язылудан баш тартырга хокуклы.

Гариза бирүчедән, Россия Федерациясенең норматив хокукый актлары нигезендә идентификация һәм аутентификация узудан, кабул итү максатын күрсәтүдән, шулай ук кабул итү өчен броньларга кирәк булган вакыт интервалы дәвамлылыгын исәпләү өчен кирәкле мәгълүматлардан тыш, башка гамәлләр башкаруны таләп итү тыела.

## 3. Административ процедураларның составы, эзлеклелеге һәм үтәү сроклары, аларны үтәү тәртибенә таләпләр, шул исәптән административ процедураларны электрон формада үтәү үзенчәлекләре, шулай ук административ процедураларны күпфункцияле үзәкләрдә үтәү үзенчәлекләре

### 3.1. Муниципаль хезмәт күрсәткәндә гамәлләр эзлеклелеген тасвирлау

3.1.1. Муниципаль хезмәт күрсәтү түбәндәге процедураларны үз эченә ала:

1) гариза бирүчегә консультацияләр бирү;

2) гариза бирүче тарафыннан бирелгән документлар комплектын кабул итү һәм карап тикшерү;

3) муниципаль хезмәт күрсәтүдә катнашучы органнарга ведомствоара запрослар җибәрү;

4) муниципаль хезмәт нәтиҗәсен әзерләү;

5) гариза бирүчегә муниципаль хезмәт нәтиҗәсен бирү (җибәрү).

### 3.2. Гариза бирүчегә консультацияләр бирү

3.2.1. Гариза бирүченең муниципаль хезмәт күрсәтү белән бәйле мәсьәләләр буенча мөрәҗәгате административ процедураны башкара башлау өчен нигез булып тора.

Административ процедураны башкару өчен җаваплы вазыйфаи зат (хезмәткәр) булып тора:

- гариза бирүче КФҮгә мөрәҗәгать иткәндә – КФҮ хезмәткәре;

- гариза бирүче Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетына мөрәҗәгать иткәндә – җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр идарәсенең бүлек белгече.

3.2.2. Гариза бирүче муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибе һәм сроклары турында консультация бирүне сорап КФҮгә шәхсән һәм телефон һәм электрон почта аша мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

КФҮ хезмәткәре гариза бирүчегә, шул исәптән тапшырыла торган документлар составы, формасы һәм муниципаль хезмәттән файдалану өчен башка мәсьәләләр буенча консультацияләр бирә.

Гариза бирүче муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибе турында мәгълүматны ирекле файдалану юлы белән КФҮ сайтыннан http://mfc16.tatarstan.ru алырга мөмкин.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган административ процедуралар гариза бирүче мөрәҗәгате көнне башкарыла.

Административ процедураларны башкару нәтиҗәсе булып тора: тапшырыла торган документлар составы, формасы һәм муниципаль хезмәттән файдалану өчен кирәкле башка мәсьәләләр буенча консультацияләр.

3.2.3. Гариза бирүче Органга телефон һәм электрон почта аша мөрәҗәгать итәргә, шулай ук Республика порталында, Органның сайтында муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибе һәм сроклары, шул исәптән тапшырыла торган документлар составы, формасы һәм муниципаль хезмәттән файдалану өчен башка мәсьәләләр буенча консультация алырга хокуклы.

Консультация бирү өчен җаваплы вазыйфаи зат Регламентның 1.3.4 пункты таләпләре нигезендә гариза бирүчегә хәбәр итә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган административ процедуралар мөрәҗәгать кергән көннән башлап өч эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Административ процедураларны башкару нәтиҗәсе булып тора: тапшырыла торган документлар составы, формасы һәм муниципаль хезмәттән файдалану өчен кирәкле башка мәсьәләләр буенча консультацияләр.

### 3.3. Гариза бирүче тарафыннан тапшырылган документлар комплектын кабул итү һәм карап тикшерү

3.3.1. КФҮ яки КФҮнең читтәге эш урыны аша муниципаль хезмәт күрсәтү өчен документлар кабул итү.

3.3.1.1. Гариза бирүче (гариза бирүченең вәкиле) муниципаль хезмәт күрсәтү турында запрос белән КФҮгә мөрәҗәгать итә һәм Регламентның 2.5 пункты нигезендә документлар тапшыра.

3.3.1.2. КФҮнең гаризалар кабул итүче хезмәткәре:

мөрәҗәгать предметын билгели;

гариза бирүченең шәхесен ачыклый;

документлар бирүче затның вәкаләтләрен тикшерә;

документларның Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән таләпләргә туры килүен тикшерә;

КФҮ АМСда гаризаның электрон формасын тутыра;

Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документлар кәгазьдә тапшырылганда, тапшырылган документларны сканерлауны гамәлгә ашыра;

КФҮ АМСдан гаризаны бастырып чыгара;

тикшерү һәм имзалау өчен гариза бирүчегә бирә;

имзаланганнан соң КФҮ АМСда имзаланган гаризаны сканерлый;

электрон формада тапшырылган документларны яки сканерланган документларның электрон рәвешләрен КФҮ АМСда йөкли, электрон дело формалаштыра;

имзаланган гаризаны һәм кәгазь документларның төп нөсхәләрен кире кайтара;

гариза бирүчегә документларны кабул итү турында расписка бирә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган административ процедуралар гариза бирүче мөрәҗәгать иткән көнне башкарыла.

Административ процедураларны башкару нәтиҗәсе булып тора: җибәрү өчен әзер гариза һәм документлар пакеты.

3.3.1.3. КФҮ хезмәткәре гариза бирүчедән Органга электрон формада кабул ителгән документлар пакетын (электрон дело пакетлары составында) гариза бирүче мөрәҗәгать иткән көннән башлап бер эш көне эчендә КФҮнең структур бүлекчәсенә җибәрә.

Административ процедураларны башкару нәтиҗәсе булып тора: электрон үзара хезмәттәшлек системасы аша Органга җибәрелгән гариза һәм документлар пакеты (электрон дело).

3.3.2. Республика порталы аша электрон формада муниципаль хезмәт күрсәтү өчен документлар кабул итү.

3.3.2.1. Гариза бирүче электрон формада гариза бирү өчен түбәндәге эшләрне башкара:

авторизацияләүне башкара;

электрон гариза формасын ача;

муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган мәгълүматларны үз эченә алган электрон гариза формасын тутыра;

электрон формадагы документларны яки документларның электрон рәвешләрен электрон гариза формасына беркетә (кирәк булганда);

электрон формада муниципаль хезмәт күрсәтү шартлары һәм тәртибе белән танышу һәм килешү фактын раслый (электрон гариза формасында ризалык турында тиешле билге куя);

хәбәр ителгән мәгълүматларның дөреслеген раслый (электрон гариза формасында тиешле билге куя);

тутырылган электрон гаризаны җибәрә (электрон гариза формасындагы тиешле төймәгә баса);

электрон гариза Регламентның 2.5.5 пункты таләпләре нигезендә имзалана;

электрон гаризаны җибәрү турында белдерү кәгазе ала.

Формалаштырылган гаризаны формат-логик тикшерү гариза бирүче тарафыннан гаризаның электрон формасының һәр кыры тутырылганнан соң башкарыла. Гаризаның электрон формасындагы дөрес тутырылмаган кыр ачыкланганда гариза бирүчегә ачыкланган хатаның характеры һәм мәгълүмати хәбәр юлы белән аны бетерү тәртибе турында гаризаның электрон формасында ук хәбәр ителә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган административ процедуралар гариза бирүче мөрәҗәгать иткән көнне башкарыла.

Административ процедураларны башкару нәтиҗәләре булып тора: Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетына электрон хезмәттәшлек системасы аша җибәрелгән электрон дело.

3.3.3. Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты тарафыннан документлар комплектын карап тикшерү.

3.3.3.1. Гариза һәм муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле башка документлар керү административ процедураны башкара башлау өчен нигез булып тора.

Административ процедураны башкару өчен җаваплы вазыйфаи зат (хезмәткәр) булып эш кәгазьләрен алып бару бүлеге белгече тора.

3.3.3.2. Гариза бирүче Органга мөрәҗәгать иткән очракта, документлар кабул итү өчен җаваплы вазыйфаи зат:

мөрәҗәгать предметын билгели;

гариза бирүченең шәхесен ачыклый;

документлар тапшыручы затның вәкаләтләрен тикшерә;

документларның Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән таләпләргә туры килүен тикшерә, тапшырылган документларның таләпләргә туры килүен тикшерә (документ күчермәләрен тиешенчә рәсмиләштерү, документларда чистартулар, өстәп язулар, сызылган сүзләр һәм башка алдан килешенмәгән төзәтүләр булмау);

дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен билгеләнгән автоматлаштырылган мәгълүмат системасына электрон формада гариза тутыра;

Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документларны кәгазьдә тапшырганда, документларны сканерлый;

гаризаны кәгазьдә бастыра;

гариза бирүчегә тикшерергә һәм имзалауга бирә;

имзалаганнан соң имзаланган гаризаны сканерлый;

электрон формада тапшырылган документларны яки сканерланган документларның электрон рәвешләрен дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен билгеләнгән автоматлаштырылган мәгълүмат системасына кертә, электрон дело формалаштыра;

имзаланган гаризаны һәм кәгазь документларны гариза бирүчегә кире кайтара;

гариза бирүчегә документларны кабул итү турында расписка бирә.

Документлар кабул итүдән баш тарту өчен нигезләр булган очракта, документлар кабул итү өчен җаваплы вазыйфаи зат, гариза бирүчегә гариза кабул итүгә каршылыклар булуы турында хәбәр итә һәм документлар кабул итүдән баш тарту өчен ачыкланган нигезләрнең эчтәлеген аңлатып, аңа документларны кире кайтара.

3.3.3.3. Карап тикшерү өчен документлар кергәннән соң, документлар кабул итү өчен җаваплы вазыйфаи зат:

эшләр номенклатурасы нигезендә гаризага номеры һәм «Документларны тикшерү» статусы бирелә, бу исә Республика порталының шәхси кабинетында чагылдырыла;

кергән электрон делоларны, шул исәптән гариза бирүче тарафыннан электрон формада теркәлгән документларны һәм документларның электрон рәвешләрен тикшерә;

документларның электрон рәвешләренең комплектлылыгын, укылуын тикшерә;

Бердәм порталга мөрәҗәгать итү юлы белән, электрон имзаның чын булу шартлары үтәлешен тикшерә (гариза бирүче тарафыннан көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон документлар тапшырылган очракта).

Регламентның 2.7.1 пунктында каралган нигезләр булганда, муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту турында карар проектын әзерли.

Көчәйтелгән квалификацияле электрон имзаны тикшерү нәтиҗәсендә аның чын булу шартлары үтәлмәү ачыкланган очракта, баш тарту турында карар проектында 63-ФЗ номерлы Федераль законның 11 статьясының аны кабул итү өчен нигез булган пунктлары булырга тиеш.

Баш тарту сәбәпләрен күрсәтеп, муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту турында карар проекты (муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләр мондый документларга карата билгеләнгән таләпләрне бозу белән бәйле булган очракта, документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләр тапшырылмаган, дөрес

булмаган һәм (яки) каршылыклы мәгълүматларны үз эченә алган, билгеләнгән таләпләрне бозып рәсмиләштерелгән документларның (мәгълүматларның) исеме турында мәгълүматны үз эченә алырга тиеш) электрон документлар әйләнеше системасы аша билгеләнгән тәртиптә килештерү өчен җибәрелә.

Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту турында карар проектын килештерү Регламентның 3.5.4 пунктында каралган тәртиптә гамәлгә ашырыла.

Регламентның 2.7.1 пунктында каралган документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләр булмаган очракта, документлар кабул итү өчен җаваплы вазыйфаи зат, гариза кергән көннән башлап бер эш көне эчендә, гаризада күрсәтелгән ысул белән, гариза бирүчегә гаризаның кергән теркәү номерын, гаризаны алу датасын, файл исемлекләренең, аңа тапшырылган документлар исемлеген, муниципаль хезмәт нәтиҗәсен алу датасын үз эченә алган гариза керү турында белдерү кәгазе җибәрә.

3.3.3.4. Регламентның 3.3.3.1, 3.3.3.3 пунктларында күрсәтелгән процедураларны башкару, техник мөмкинлек булганда, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен билгеләнгән автоматлаштырылган мәгълүмат системасыннан файдаланып, автомат режимда гамәлгә ашырыла.

3.3.3.5. Регламентның 3.3.3 пункты белән билгеләнә торган процедуралар карап тикшерү өчен гариза кергән көннән башлап бер эш көне эчендә башкарыла.

Административ процедураларны башкару нәтиҗәләре булып тора: карап тикшерүгә кабул ителгән документлар комплекты яки муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту турында карар проекты.

### 3.4. Муниципаль хезмәт күрсәтүдә катнашучы органнарга ведомствоара запрослар җибәрү

3.4.1. Административ процедураны башкара башлау өчен нигез булып административ процедураны башкаруга вәкаләтле вазыйфаи зат (хезмәткәр) тарафыннан документларны кабул итү өчен җаваплы вазыйфаи заттан (хезмәткәрдән) гариза бирүчедән кабул ителгән документларны алу тора.

Административ процедураны башкару өчен җаваплы вазыйфаи зат (хезмәткәр) булып җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр идарәсенең бүлек белгече тора.

3.4.2. Ведомствоара запросларны җибәрү өчен җаваплы вазыйфаи зат, Регламентның 2.6 пунктында каралган документларны һәм мәгълүматларны тапшыру турында запросларны ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы аша (техник мөмкинлек булмаганда – башка ысуллар белән) электрон формада формалаштыра һәм җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган административ процедуралар карап тикшерү өчен гариза кабул ителгән көнне башкарыла.

Административ процедураларны башкару нәтиҗәләре булып тора: хакимият органнарына һәм (яки) хакимият органнарының ведомство буйсынуындагы оешмаларына җибәрелгән запрослар.

3.4.3. Мәгълүматлар белән тәэмин итүчеләрнең белгечләре, ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы аша кергән запрослар нигезендә, сорала торган документларны (мәгълүматны) бирәләр яки муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документ һәм (яки) мәгълүмат булмау турында белдерү кәгазьләре (алга таба – баш тарту турында белдерү кәгазе) җибәрәләр.

Административ процедураларны башкару нәтиҗәләре булып тора: гамәлдәге законнарда билгеләнгән срокларда муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документлар (мәгълүматлар) яисә ведомствоара запрослар җибәрү өчен җаваплы вазыйфаи затка җибәрелгән баш тарту турында белдерү кәгазе.

3.4.4. Ведомствоара запрослар җибәрү өчен җаваплы вазыйфаи зат:

ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы аша сорала торган муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны (мәгълүматларны) яисә документ һәм (яки) мәгълүмат булмаганда баш тарту турында белдерү кәгазен ала;

Регламентның 2.7.1 пунктында нигезләр булганда, муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту турында карар проектын әзерли.

Баш тарту сәбәпләрен күрсәтеп, муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту турында карар проекты (муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләр мондый документларга карата билгеләнгән таләпләрне бозу белән бәйле булган очракта, документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләр тапшырылмаган, дөрес булмаган һәм (яки) каршылыклы мәгълүматларны үз эченә алган, билгеләнгән таләпләрне бозып рәсмиләштерелгән документларның (мәгълүматларның) исеме турында мәгълүматны үз эченә алырга тиеш) электрон документлар әйләнеше системасы аша билгеләнгән тәртиптә килештерү өчен җибәрелә.

Муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту өчен Регламентның 2.8.2 пунктында күрсәтелгән нигезләр ачыкланганда, муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту турында карар проектын әзерли.

Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту турында карар проектын, муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту турында карар проектын, муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе проектын килештерү Регламентның 3.5.4 пунктында каралган тәртиптә гамәлгә ашырыла.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган административ процедуралар бер эш көне эчендә башкарыла.

Административ процедураларны башкару нәтиҗәләре булып тора: муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документлар (мәгълүматлар), яисә ведомствоара запрослар җибәрү өчен җаваплы вазыйфаи затка җибәрелгән баш тарту турында белдерү кәгазе, муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту турында карар проекты, муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту турында карар проекты, муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе проекты.

3.4.5. Регламентның 3.4.2, 3.4.4, 3.4.5 пунктларында күрсәтелгән процедураларны башкару, техник мөмкинлек булганда, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен билгеләнгән автоматлаштырылган мәгълүмат системасыннан файдаланып, шул исәптән Регламентның 2.13 пункты нигезендә гариза теркәлгән вакыттан башлап, автомат режимда гамәлгә ашырыла.

3.4.6. Регламентның 3.4 пунктында күрсәтелгән административ процедураларны башкаруның максималь срогы алты эш көне тәшкил итә.

## 3.5. Муниципаль хезмәт нәтиҗәсен әзерләү

3.5.1. Административ процедураны башкару өчен нигез булып, муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле ведомствоара запрослар җибәрү өчен җаваплы вазыйфаи заттан керү документлар (мәгълүматлар) тора.

Административ процедураны башкару өчен җаваплы вазыйфаи зат булып җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр идарәсенең бүлек белгече (алга таба – муниципаль хезмәт нәтиҗәсен әзерләү өчен җаваплы вазыйфаи зат) тора.

3.5.2. Муниципаль хезмәт нәтиҗәсен әзерләү өчен җаваплы вазыйфаи зат:

җир участогын карау һәм билгеләнгән таләпләргә туры килү предметына бәяләү өчен урынга бару кирәклеге турында карар кабул итә;

җир участогын карау һәм билгеләнгән таләпләргә туры килү предметына бәяләү өчен урынга бару кирәк булган очракта, карауны һәм фотофиксацияләүне гамәлгә ашыра, территориядән файдалануның аерым шартлары булган зоналарның урнашу чикләрен билгели;

муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле, формалаштырылган документлар комплектын карап тикшерә;

Регламентның 2.8.2 пунктында күрсәтелгән муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр ачыкланганда, муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту турында карар проектын әзерли;

Граждан торак пункт, бакчачылык чикләрендә индивидуаль торак төзелеше, шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен җир участогы бирү турында мөрәҗәгать итсә, граждан яки крестьян (фермер) хуҗалыгы крестьян (фермер) хуҗалыгы тарафыннан эшчәнлек алып бару өчен җир участогы бирү турында гариза бирсә, билгеләнгән тәртиптә җир участогы бирелачәге турында хәбәрне бастырып чыгару өчен җибәрә һәм аукционда катнашырга теләүче затлардан гаризалар җыя һәм бу хакта гариза бирүчегә хәбәр итә.

Регламентның 3.5.2 пунктында күрсәтелгән административ процедураларны үтәү срогы ике эш көне тәшкил итә, җир участогын карап чыгу һәм билгеләнгән таләпләргә туры килү предметына бәяләү өчен урынга барырга кирәк булган очракта – 11 эш көне.

Административ процедураларны башкару нәтиҗәләре булып тора: карау материаллары, муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту турында карар проекты, билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгару өчен җибәрелгән җир участогы бирү турында белдерү, муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле формалаштырылган документлар комплекты.

3.5.3. Муниципаль хезмәт нәтиҗәсен әзерләү өчен җаваплы вазыйфаи зат:

җир участогын сату буенча аукционда яки җир участогын арендалау шартнамәсе төзү хокукына аукционда катнашырга ниятләгән затлардан җир участогы бирү турында хәбәр урнаштырылганнан соң утыз көн эчендә гариза кергән очракта, муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту турында карар проектын әзерли;

муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту өчен Регламентның 2.8.2 пунктында каралган нигезләр булмаган очракта, муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны карап тикшерү нәтиҗәләре буенча Регламентның 2.3.1 пунктындагы 1-5 пунктчалары нигезендә муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе проектын әзерли;

әзерләнгән муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе проектын электрон документ әйләнеше системасы аша билгеләнгән тәртиптә килештерү өчен җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнгән административ процедуралар бер эш көне эчендә башкарыла.

Административ процедураларны башкару нәтиҗәсе булып тора: килештерүгә җибәрелгән муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе проекты.

3.5.4. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту, муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе проектын (алга таба – документлар проектлары) килештерү һәм имзалау муниципаль хезмәт нәтиҗәсен әзерләү өчен җаваплы структур бүлекчә җитәкчесе, Орган җитәкчесе урынбасары, Орган җитәкчесе тарафыннан башкарыла.

Әзерләнгән һәм кимчелекләре булган документлар проектлары муниципаль хезмәт нәтиҗәсен әзерләү өчен җаваплы затка кире кайтарыла.

Кимчелекләр бетерелгәннән соң, документлар проектлары килештерү һәм имзалау өчен кабат тапшырыла.

Орган җитәкчесе документлар проектларын карап тикшергәндә, регламентның вазыйфаи затлары тарафыннан административ процедураларны үтәү срокларын, аларның эзлеклелеген һәм тулылыгын, электрон документ әйләнеше системасында вәкаләтле вазыйфаи затларның килешүләре булуны тикшерә.

Административ процедураларны үтәү сроклары, аларның эзлеклелеге һәм тулылыгы өлешендә хокук бозулар ачыкланган очракта, Орган җитәкчесе Регламентның 4.3 пункты нигезендә хокук бозуларга юл куйган затларны җаваплылыкка тарту инициативасы белән чыга.

Әлеге пункт белән билгеләнгән административ процедуралар ике эш көне эчендә башкарыла.

Административ процедураларны башкару нәтиҗәләре булып тора: муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту турында карар, Регламентның 2.3.1 пункты нигезендә муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе.

3.5.5. Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен әзерләү өчен җаваплы вазыйфаи зат:

гариза бирүче тарафыннан Регламент 2.3.1 пунктының 1 – 4 пунктчаларында күрсәтелгән муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен КФҮдә алу ысулы сайланган очракта, шартнамә проектының кәгазьдә ике нөсхәсен әзерләүне тәэмин итә һәм Органның вәкаләтле вазыйфаи затына имзалауга җибәрә;

гариза бирүче тарафыннан муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен КФҮдә алу ысулы сайланган очракта имзаланган кәгазьдәге документ проектларын бирү өчен КФҮгә җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнгән административ процедуралар өч эш көне эчендә башкарыла.

Административ процедураларны башкару нәтиҗәләре булып тора: Регламентның 2.3.1 пункты белән каралган кәгазьдәге шартнамә проектлары.

3.5.6. Регламентның 3.5.3-3.5.5 пунктларда күрсәтелгән процедураларны башкару техник мөмкинлек булган очракта, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен билгеләнгән автоматлаштырылган мәгълүмат системасыннан файдаланып, автомат режимда гамәлгә ашырыла.

Регламентның 3.5 пунктында күрсәтелгән административ процедураларны башкаруның максималь срогы 14 эш көне тәшкил итә, җир участогы бирү турында хәбәр бастырып чыгарылган очракта – 47 эш көне.

3.6. Гариза бирүчегә муниципаль хезмәт нәтиҗәсен бирү (җибәрү)

3.6.1. Административ процедураны башкара башлау өчен нигез булып административ процедураны башкару өчен җаваплы вазыйфаи зат тарафыннан муниципаль хезмәт күрсәтүне раслаучы документны алу тора.

Административ процедураны башкару өчен җаваплы вазыйфаи зат булып җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр идарәсенең бүлек белгече (алга таба – документлар бирү (җибәрү) өчен җаваплы вазыйфаи зат) тора.

3.6.2. Документлар бирү (җибәрү) өчен җаваплы вазыйфаи зат:

муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе турында мәгълүматларны теркәүне һәм, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен билгеләнгән автоматлаштырылган мәгълүмат системасы документларын алып бару системасына һәм шәһәр төзелеше эшчәнлеген тәэмин итүнең мәгълүмат системасына кертүне тәэмин итә;

гариза бирүчегә (аның вәкиленә) гаризада күрсәтелгән ысул белән муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе турында һәм муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен Органда яки КФҮдә алу мөмкинлеге турында хәбәр итә.

Процедураларны башкару, техник мөмкинлек булганда, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен билгеләнгән автоматлаштырылган мәгълүмат системасыннан файдаланып, автомат режимда гамәлгә ашырыла.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган административ процедуралар Органның вәкаләтле вазыйфаи заты (Орган) тарафыннан муниципаль хезмәт күрсәтүне (күрсәтүдән баш тартуны) раслаучы документ имзаланган көнне башкарыла.

Административ процедураларны башкару нәтиҗәсе булып тора: мәгълүмат системаларында муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәләре турында мәгълүматлар

урнаштыру, гариза бирүчегә (аның вәкиленә) муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе һәм аны алу ысуллары турында хәбәр итү.

3.6.3. Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен бирү (җибәрү) тәртибе:

3.6.3.1. Гариза бирүче муниципаль хезмәт нәтиҗәсен сорап КФҮгә мөрәҗәгать иткәндә, КФҮ хезмәткәре гариза бирүчегә муниципаль хезмәт нәтиҗәсен бирә. Гариза бирүченең таләбе буенча, электрон документның кәгазьдәге нөсхәсе белән бергә, алынмалы йөрткечкә яздыру юлы белән, аңа электрон документ нөсхәсе бирелергә мөмкин.

Гариза бирүче тарафыннан шартнамә проектын имзалау КФҮдә башкарыла.

Шартнамә төзегәндә КФҮ хезмәткәре документларны имзалаучы затның вәкаләтләрен тикшерә. Документларны имзаларга гариза бирүченең вәкаләтле вәкиле мөрәҗәгать иткән очракта, гариза бирүче вәкиленең вәкаләтләрен раслаучы документларны сканерлый һәм алар турында мәгълүматларны КФҮ АМСка кертә.

Гариза бирүче (гариза бирүченең документларны имзалауга вәкаләтле вәкиле) өчен) шартнамәнең ике нөсхәсен имзалый, икенче ягыннан үз имзасы һәм мөһере белән беркетә (гариза бирүче юридик зат булган очракта).

КФҮ хезмәткәре шартнамәне имзалау датасын куя һәм бер нөсхәне гариза бирүчегә (гариза бирүче вәкиленә) бирә.

Гариза бирүче тарафыннан шартнамә имзаланганнан соң бер эш көненнән дә соңга калмыйча, КФҮ органга шартнамәләрнең нөсхәләрен җибәрә.

Гариза бирүчегә җибәрелгән шартнамәләр проектлары, гариза бирүче тарафыннан имзаланырга һәм әлеге шартнамәләр проектларын алган көннән башлап 30 көннән дә соңга калмыйча КФҮгә тапшырылырга тиеш.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган административ процедуралар, КФҮнең эш регламентында билгеләнгән срокларда, гариза бирүче килгән көнне чират тәртибендә башкарыла.

Административ процедураларны башкару нәтиҗәләре булып тора: КФҮ АМСта муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен бирү фактын теркәү; гариза бирүче имзалаган һәм Органга җибәрелгән шартнамә.

3.6.3.2. Гариза бирүче Республика порталы аша муниципаль хезмәт күрсәтүне сорап мөрәҗәгать иткәндә, Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының вәкаләтле вазыйфаи затының (Орган тарафыннан) көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзаланган, муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе булган документның электрон рәвеше автомат рәвештә гариза бирүчегә җибәрелә.

Гариза бирүче шартнамә проектларын Республика порталының шәхси кабинетында 30 календарь көн эчендә көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаларга хокуклы.

30 календарь көн узгач, гариза бирүчегә шартнамәне имзалау срогы чыгу турында мәгълүмат килә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган административ процедуралар Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының вәкаләтле вазыйфаи заты (Органы) тарафыннан муниципаль хезмәт күрсәтүне (күрсәтүдән баш тартуны) раслаучы документ имзаланган көнне башкарыла.

Административ процедураларны башкару нәтиҗәсе булып тора: Республика порталыннан файдаланып, гариза бирүчегә муниципаль хезмәт күрсәтүне (шул исәптән муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тартуны) раслаучы документ җибәрү (бирү).

3.6.3.3. Гариза бирүче муниципаль хезмәт нәтиҗәсен алу өчен Органга мөрәҗәгать иткәндә, документларны бирү (җибәрү) өчен җаваплы вазыйфаи зат гариза бирүчегә муниципаль хезмәт нәтиҗәсен бирә. Гариза бирүче таләбе буенча, кәгазьдәге электрон

документ нөсхәсе белән бергә аңа күчереп йөрткечтә электрон документ нөсхәсе бирелергә мөмкин.

Гариза бирүче тарафыннан шартнамә проектын имзалау Органда башкарыла.

Шартнамәне имзалаганда, документларны бирү (җибәрү) өчен җаваплы вазыйфаи зат документларны имзалаучы затның вәкаләтләрен тикшерә. Гариза бирүченең документларны имзаларга вәкаләтле вәкиле мөрәҗәгать иткән очракта, гариза бирүче вәкиленең вәкаләтләрен раслый торган документларны сканерлый һәм алар турында мәгълүматларны дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен билгеләнгән автоматлаштырылган мәгълүмат системасына кертә.

Гариза бирүче (гариза бирүченең документларны имзалауга вәкаләтле вәкиле) шартнамәнең ике нөсхәсен имзалый, икенче ягыннан үз имзасы һәм мөһере белән беркетә (гариза бирүче юридик зат булган очракта).

Документлар бирү (җибәрү) өчен җаваплы вазыйфаи зат шартнамәне имзалау датасын куя һәм бер нөсхәне гариза бирүчегә (гариза бирүче вәкиленә) бирә.

Гариза бирүчегә җибәрелгән шартнамә проекты, гариза бирүче тарафыннан әлеге документ проекты алынган көннән башлап 30 көннән дә соңга калмыйча, имзаланырга һәм органга тапшырылырга тиеш.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган административ процедуралар чират тәртибендә, гариза бирүче килгән көнне Органның эчке хезмәт тәртибе кагыйдәләре белән билгеләнгән срокларда гамәлгә ашырыла.

Административ процедураларны башкару нәтиҗәсе булып тора: дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен билгеләнгән автоматлаштырылган мәгълүмат системасында муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен бирү фактын теркәү.

## 3.7. Техник хаталарны төзәтү

3.7.1. Муниципаль хезмәт нәтиҗәсе булып торган документта техник хата ачыкланган очракта, гариза бирүче Органга тапшыра:

техник хатаны төзәтү турында гариза (әлеге Регламентка 11 нче кушымта);

гариза бирүчегә муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе буларак бирелгән техник хаталы документ;

техник хата булуны раслаучы юридик көчкә ия документлар.

Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе булып торган документта күрсәтелгән мәгълүматлардагы техник хатаны төзәтү турында гариза, гариза бирүче (вәкаләтле вәкил) тарафыннан почта аша (шул исәптән электрон почтадан файдаланып) яисә Республика порталы яки КФҮ аша бирелә.

3.7.2. Документларны кабул итү өчен җаваплы вазыйфаи зат техник хатаны төзәтү турында гаризаны кабул итүне гамәлгә ашыра, теркәлгән документлары белән бергә гаризаны терки һәм документларны эшкәртү өчен җаваплы вазыйфаи затка бирә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган административ процедуралар гариза теркәлгән датадан башлап бер эш көне эчендә башкарыла.

Административ процедураны башкару нәтиҗәсе булып тора: кабул ителгән, теркәлгән һәм карап тикшерү өчен документларны эшкәртү өчен җаваплы вазыйфаи затка җибәрелгән гариза.

3.7.3. Документларны эшкәртү өчен җаваплы вазыйфаи зат документларны карап тикшерә һәм муниципаль хезмәт нәтиҗәсе булып торган документка төзәтмәләр кертү максатында, Регламентның 3.5 пунктында каралган процедураларны гамәлгә ашыра һәм төзәтелгән документны, имза куйдырып, шәхсән гариза бирүчегә (вәкаләтле вәкилгә) бирә, төп нөсхәсен гариза бирүчедән (вәкаләтле вәкилдән) алып, техник хата булган документны гариза бирүчегә (вәкаләтле вәкилгә) бирә яки техник хаталы документның төп нөсхәсен Органга

тапшырганда документны алу мөмкинлеге турында хатны гариза бирүчегә почта аша (электрон почта аша) җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган административ процедуралар техник хата ачыкланганнан яисә теләсә кайсы кызыксынган заттан җибәрелгән хата турында гариза кергәннән соң ике эш көне эчендә башкарыла.

Административ процедураны башкару нәтиҗәсе булып тора: гариза бирүчегә бирелгән (җибәрелгән) документ.

## 4. Муниципаль хезмәт күрсәтүне контрольдә тоту тәртибе һәм формалары

### 4.1. Җаваплы вазыйфаи затлар тарафыннан Регламент нигезләмәләрен һәм муниципаль хезмәт күрсәтүгә таләпләрне билгели торган башка норматив хокукый актларны үтәүне һәм башкаруны, шулай ук алар тарафыннан карарлар кабул итүне агымдагы контрольдә тоту тәртибе

Муниципаль хезмәт күрсәтү тулылыгын һәм сыйфатын контрольдә тоту гариза бирүчеләрнең хокукларын бозу очракларын ачыклау һәм бетерүне, муниципаль хезмәт күрсәтү процедураларының үтәлешенә тикшерүләр үткәрү, җирле үзидарә органы вазыйфаи затларының гамәлләренә (гамәл кылмавына) карарлар әзерләүне үз эченә ала.

Административ процедураларның үтәлешен контрольдә тоту формалары булып түбәндәгеләр тора:

1) муниципаль хезмәт күрсәтү буенча документ проектларын тикшерү һәм килештерү;

2) эш башкаруны алып баруга карата билгеләнгән тәртиптә үткәрелә торган тикшерүләр;

3) муниципаль хезмәт күрсәтү процедураларының үтәлеше буенча билгеләнгән тәртиптә контроль тикшерүләр үткәрү.

Агымдагы контроль максатларында электрон мәгълүматлар базасында булган мәгълүматлар, хезмәт корреспонденциясе, административ процедураларны башкаруны гамәлгә ашыручы вазыйфаи затларның телдән һәм язма мәгълүматы, тиешле документларны исәпкә алу журналлары һәм башка мәгълүматлар файдаланыла.

Муниципаль хезмәт күрсәткәндә һәм карарлар кабул иткәндә гамәлләр кылуга контрольне гамәлгә ашыру өчен җирле үзидарә орган җитәкчесенә муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәләре турында белешмәләр бирелә.

Административ процедураларның срокларын, эзлеклелеген һәм эчтәлеген бозу очраклары һәм сәбәпләре турында вазыйфаи затлар кичекмәстән муниципаль хезмәт күрсәтүче орган җитәкчесенә хәбәр итәләр, шулай ук кимчелекләрне бетерү буенча ашыгыч чаралар күрәләр.

Муниципаль хезмәт күрсәтү буенча административ процедураларда билгеләнгән гамәлләрнең эзлеклелеге үтәлешен агымдагы контрольдә тоту муниципаль хезмәт күрсәтү буенча эшне оештыру өчен җаваплы җирле үзидарә органы җитәкчесенең урынбасары, муниципаль хезмәт күрсәтү буенча эш оештыруны гамәлгә ашыручы бүлек башлыгы тарафыннан гамәлгә ашырыла.

Агымдагы контрольне гамәлгә ашыручы вазыйфаи затларның исемлеге җирле үзидарә органының структур бүлекчәләре турындагы нигезләмәләр һәм вазыйфаи регламентлар нигезендә билгеләнә.

### 4.2. Муниципаль хезмәт күрсәтү тулылыгын һәм сыйфатын планлы һәм планнан тыш тикшерүләрне гамәлгә ашыру тәртибе һәм вакыты, шул исәптән муниципаль

хезмәт күрсәтү тулылыгын һәм сыйфатын контрольдә тотуның тәртибе һәм формалары

Контроль тикшерүләр планлы (җирле үзидарә органының ярты еллык яки еллык эш планнары нигезендә гамәлгә ашырылырга) һәм планнан тыш булырга мөмкин. Тикшерүләр үткәргәндә муниципаль хезмәт күрсәтү (комплекслы тикшерүләр) белән бәйле, яки гариза бирүченең конкрет мөрәҗәгате буенча барлык мәсьәләләр каралырга мөмкин.

4.3. Муниципаль хезмәт күрсәтүче органның вазыйфаи затларының муниципаль хезмәт күрсәтү барышында кабул ителә (гамәлгә ашырыла) торган карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) өчен җаваплылыгы

Үткәрелгән тикшерүләрнең нәтиҗәләре буенча, гариза бирүчеләрнең хокукларын бозулар ачыкланган очракта, гаепле затлар Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплылыкка тартылалар.

Җирле үзидарә органы җитәкчесе гариза бирүчеләрнең мөрәҗәгатьләре үз вакытында карап тикшерелмәү өчен җаваплы.

Җирле үзидарә органының структур бүлекчәсе җитәкчесе (җитәкче урынбасары) әлеге Регламентның 3 бүлегендә күрсәтелгән административ гамәлләрнең үз вакытында һәм (яки) тиешенчә үтәлмәве өчен җаваплы.

Муниципаль хезмәт күрсәтү барышында кабул ителә (гамәлгә ашырыла) торган карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) өчен вазыйфаи затлар һәм башка муниципаль хезмәткәрләр законда билгеләнгән тәртиптә җаваплы.

4.4. Муниципаль хезмәт күрсәтүне, шул исәптән гражданнар, аларның берләшмәләре һәм оешмалар ягыннан контрольдә тоту тәртибенә һәм формаларына карата таләпләрне характерлаучы нигезләмәләр

Муниципаль хезмәт күрсәтүне гражданнар, аларның берләшмәләре һәм оешмалар ягыннан контрольдә тоту муниципаль хезмәт күрсәткәндә җирле үзидарә органы эшчәнлегенең ачыклыгы, муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибе һәм муниципаль хезмәт күрсәтү процессында мөрәҗәгатьләрне (шикаятьләрне) судка кадәр карап тикшерү мөмкинлеге турында тулы, актуаль һәм дөрес мәгълүмат алу аша гамәлгә ашырыла.

5. Муниципаль хезмәт күрсәтүче органның, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча күпфункцияле үзәкнең, 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясының 1.1 өлешендә күрсәтелгән оешмаларның, шулай ук аларның вазыйфаи затларының, муниципаль хезмәткәрләренең, хезмәткәрләренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү тәртибе

5.1. Муниципаль хезмәттән файдаланучылар муниципаль хезмәт күрсәтүче органның, муниципаль хезмәт күрсәтүче орган вазыйфаи затының, муниципаль хезмәткәрнең, муниципаль хезмәт күрсәтүче орган җитәкчесенең, күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең, 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясының 1.1 өлешендә каралган оешмаларның, шулай ук аларның хезмәткәрләренең гамәлләренә (гамәл кылмавына) судка кадәр тәртиптә шикаять бирергә хокуклы.

Гариза бирүче шикаять белән мөрәҗәгать итәргә мөмкин, шул исәптән түбәндәге очракларда:

1) муниципаль хезмәт күрсәтү турында запросны, 210-ФЗ номерлы Федераль законның 15.1 статьясында күрсәтелгән запросны теркәү срогын бозу;

2) муниципаль хезмәт күрсәтү срогын бозу. Күрсәтелгән очракта гариза бирүче тарафыннан күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү, 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясының 1.3 өлешендә билгеләнгән тәртиптә, карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять бирелә торган күпфункцияле үзәккә тулы күләмдә тиешле муниципаль хезмәт күрсәтү буенча функция йөкләнгән очракта мөмкин;

3) муниципаль хезмәт күрсәтү өчен гариза бирүчедән Россия Федерациясенең норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасының норматив хокукый актларында, муниципаль хокукый актларда тапшыру яки гамәлгә ашыру каралмаган документлар яки мәгълүмат яисә эшләрне гамәлгә ашыруны таләп итү;

4) муниципаль хезмәт күрсәтү өчен гариза бирүчедән Россия Федерациясенең норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасының норматив хокукый актларында, муниципаль хокукый актларда тапшыру каралган документларны кабул итүдән баш тарту;

5) баш тарту өчен нигезләр федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актларында, муниципаль хокукый актларда каралмаган очракта, муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту. Күрсәтелгән очракта гариза бирүче тарафыннан күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү, 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясының 1.3 өлешендә билгеләнгән тәртиптә, карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять бирелә торган күпфункцияле үзәккә тулы күләмдә тиешле муниципаль хезмәт күрсәтү буенча функция йөкләнгән очракта мөмкин;

6) муниципаль хезмәт күрсәткәндә гариза бирүчедән Россия Федерациясенең норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасының норматив хокукый актларында, муниципаль хокукый актларда каралмаган түләү таләп итү;

7) муниципаль хезмәт күрсәтүче органның, муниципаль хезмәт күрсәтүче орган вазыйфаи затының, күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең, 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясының 1.1 өлешендә каралган оешмаларның яки аларның хезмәткәрләренең муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда җибәрелгән ялгышларны һәм хаталарны төзәтүдән баш тартуы яисә андый төзәтүләрнең билгеләнгән срогын бозу. Күрсәтелгән очракта гариза бирүче тарафыннан күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү, 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясының 1.3 өлешендә билгеләнгән тәртиптә, карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять бирелә торган күпфункцияле үзәккә тулы күләмдә тиешле муниципаль хезмәт күрсәтү буенча функция йөкләнгән очракта мөмкин;

8) муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәләре буенча документлар бирү срогын яки тәртибен бозу;

9) туктату нигезләре федераль законнарда һәм аларга туры китереп кабул ителгән Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы законнарында һәм башка норматив хокукый актларында, муниципаль хокукый актларда каралмаган очракта муниципаль хезмәт күрсәтүне туктату. Күрсәтелгән очракта гариза бирүче тарафыннан күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү, 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясының 1.3 өлешендә билгеләнгән тәртиптә, карарларына һәм гамәлләренә

(гамәл кылмавына) шикаять бирелә торган күпфункцияле үзәккә тулы күләмдә тиешле муниципаль хезмәт күрсәтү буенча функция йөкләнгән очракта мөмкин;

10) муниципаль хезмәт күрсәткәндә гариза бирүчедән 210-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясындагы 1 өлешнең 4 пунктында каралган очраклардан тыш, муниципаль хезмәт күрсәтүдән яисә муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән беренче тапкыр баш тартканда булмавы һәм (яки) дөрес булмавы күрсәтелмәгән документларны яки мәгълүматны таләп итү. Күрсәтелгән очракта гариза бирүче тарафыннан күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү, 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясының 1.3 өлешендә билгеләнгән тәртиптә, карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять бирелә торган күпфункцияле үзәккә тулы күләмдә тиешле муниципаль хезмәт күрсәтү буенча функция йөкләнгән очракта мөмкин.

5.2. Шикаять язмача кәгазьдә, электрон формада муниципаль хезмәт күрсәтүче органга, күпфункцияле үзәккә яисә күпфункцияле үзәкне гамәлгә куючы булып торган тиешле дәүләт хакимияте органына (алга таба – күпфункцияле үзәкне гамәлгә куючы), шулай ук 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясының 1.1 өлешендә каралган оешмаларга бирелә. Муниципаль хезмәт күрсәтүче орган җитәкчесенең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаятьләр югары органга (ул булганда) бирелә яисә ул булмаган очракта, турыдан-туры муниципаль хезмәт күрсәтүче орган җитәкчесе тарафыннан карала. Күпфункцияле үзәк хезмәткәренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаятьләр әлеге күпфункцияле үзәк җитәкчесенә бирелә. Күпфункцияле үзәкнең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаятьләр күпфункцияле үзәкне гамәлгә куючыга яки Татарстан Республикасының норматив хокукый акты белән вәкаләтләнгән вазыйфаи затка бирелә. 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясының 1.1 өлешендә каралган оешмалар хезмәткәрләренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаятьләр әлеге оешмалар җитәкчеләренә бирелә.

Муниципаль хезмәт күрсәтүче органның, муниципаль хезмәт күрсәтүче орган вазыйфаи затының, муниципаль хезмәткәренең, муниципаль хезмәт күрсәтүче орган җитәкчесенең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять почта аша, күпфункцияле үзәк аша, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән, муниципаль хезмәт күрсәтүче органның рәсми сайтыннан, Бердәм порталдан яисә Республика порталыннан, судка кадәр шикаять бирү буенча мәгълүмат системасыннан файдаланып җибәрелергә мөмкин, шулай ук гариза бирүчене шәхси кабул иткәндә кабул ителергә мөмкин. Күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять почта аша, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән, күпфункцияле үзәкнең рәсми сайтыннан, Бердәм порталдан яисә Республика порталыннан, судка кадәр шикаять бирү буенча мәгълүмат системасыннан файдаланып җибәрелергә мөмкин, шулай ук гариза бирүчене шәхси кабул иткәндә кабул ителергә мөмкин.

210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясының 1.1 өлешендә каралган оешмаларның, шулай ук аларның хезмәткәрләренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять почта аша, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән, әлеге оешмаларның рәсми сайтларыннан, Бердәм порталдан яисә Республика порталыннан файдаланып җибәрелергә мөмкин, шулай ук гариза бирүчене шәхси кабул иткәндә кабул ителергә мөмкин.

5.3. Шикаятьтә түбәндәге мәгълүматлар булырга тиеш:

1) карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять бирелә торган муниципаль хезмәт күрсәтүче органның, муниципаль хезмәт күрсәтүче орган вазыйфаи затының яисә муниципаль хезмәткәренең, күпфункцияле үзәкнең, аның

җитәкчесенең һәм (яки) хезмәткәренең, 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясының 1.1 өлешендә каралган оешмаларның, аларның җитәкчеләренең һәм (яки) хезмәткәрләренең исеме;

2) гариза бирүченең – физик затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта), яшәү урыны турында мәгълүматлар яисә гариза бирүченең – юридик затның урнашу урыны турында мәгълүматлар, шулай ук элемтә өчен телефон номеры (номерлары), электрон почта адресы (булган очракта) һәм гариза бирүчегә җавап җибәрелергә тиешле почта адресы;

3) муниципаль хезмәт күрсәтүче органның, муниципаль хезмәт күрсәтүче орган вазыйфаи затының яисә муниципаль хезмәткәренең, күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең, 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясының 1.1 өлешендә каралган оешмаларның, аларның хезмәткәрләренең шикаять белдерелә торган карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) турында мәгълүматлар;

4) гариза бирүченең муниципаль хезмәт күрсәтүче органның, муниципаль хезмәт күрсәтүче орган вазыйфаи затының яисә муниципаль хезмәткәренең, күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең, 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясының 1.1 өлешендә каралган оешмаларның, аларның хезмәткәрләренең карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) белән нинди нигездә килешмәвенең дәлилләре.

5.4. Кергән шикаять, кергән көннән соң килүче эш көненнән дә соңга калмыйча теркәлергә тиеш.

5.5. Муниципаль хезмәт күрсәтүче органга, күпфункцияле үзәккә, күпфункцияле үзәкне гамәлгә куючы органга, 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясының 1.1 өлешендә каралган оешмаларга яисә югары органга (ул булганда) кергән шикаять, аны теркәгән көннән башлап унбиш эш көнендә, ә муниципаль хезмәт күрсәтүче органның, күпфункцияле үзәкнең, 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясының 1.1 өлешендә каралган оешмаларның гариза бирүчедән документларны кабул итүдән яисә җибәрелгән ялгышларны һәм хаталарны төзәтүдән баш тартуына шикаять бирелгән очракта яки мондый төзәтүләрнең билгеләнгән срогын бозуга шикаять бирелгән очракта – аны теркәгән көннән башлап биш эш көне эчендә карап тикшерелергә тиеш.

5.6. Шикаятьне карап тикшерү нәтиҗәләре буенча түбәндәге карарларның берсе кабул ителә:

1) шикаять канәгатьләндерелә, шул исәптән кабул ителгән карарны гамәлдән чыгару, хезмәт күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда җибәрелгән хаталарны һәм ялгышларны төзәтү, Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында, муниципаль хокукый актларда түләтү каралмаган акчаларны гариза бирүчегә кире кайтару рәвешендә;

2) шикаятьне канәгатьләндерүдән баш тартыла.

Әлеге пунктта күрсәтелгән карар кабул ителгән көннән соң килүче көннән дә соңга калмый, гариза бирүчегә язма рәвештә һәм гариза бирүченең теләге буенча электрон формада шикаятьләрне карап тикшерү нәтиҗәләре турында дәлилләнгән җавап җибәрелә.

5.7. Шикаять канәгатьләндерелергә тиеш дип танылган очракта, гариза бирүчегә шикаятьне карап тикшерү нәтиҗәләре турында җавапта, муниципаль хезмәт күрсәткәндә ачыкланган кимчелекләрне тиз арада бетерү максатында, муниципаль хезмәт күрсәтүче орган, күпфункцияле үзәк яисә 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясының 1.1 өлешендә күрсәтелгән оешма тарафыннан гамәлгә ашырыла торган гамәлләр турында мәгълүмат бирелә, шулай ук тудырылган уңайсызлыклар өчен гафу үтенелә һәм муниципаль хезмәттән

файдалану максатында гариза бирүче башкарырга тиешле алдагы гамәлләр турында мәгълүмат күрсәтелә.

5.8. Шикаять канәгатьләндерелергә тиеш түгел дип танылган очракта, гариза бирүчегә шикаятьне карап тикшерү нәтиҗәләре турында җавапта кабул ителгән карар сәбәпләре турында дәлилләнгән аңлатмалар, шулай ук кабул ителгән карарга шикаять бирү тәртибе турында мәгълүмат бирелә.

5.9. Шикаятьне карап тикшерү барышында яки аның нәтиҗәләре буенча административ хокук бозулар яки җинаять составы билгеләре ачыкланган очракта, шикаятьләрне карап тикшерү вәкаләтләре бирелгән вазыйфаи зат, хезмәткәр булган материалларны кичекмәстән прокуратура органнарына җибәрә.

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы Н.И. Галиева

Муниципаль милектәге җир участогын сатулар үткәрмичә милеккә, арендага, даими (сроксыз) файдалануга, түләүсез файдалануга бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына
1 нче кушымта

Гариза бирүченең җир участогын сатулар үткәрмичә алу хокукын раслый торган документлар исемлеге

| № | Сатулар үткәрмичә җир участогын бирү нигезе | Җир участогын бушлай яки түләү нигезендә бирү гамәлгә ашырыла торган хокук төре | Гариза бирүче | Җир участогы | Гариза бирүченең җир участогын сатулар үткәрмичә алу хокукын раслаучы һәм җир участогына хокук алу турында гаризага теркәлә торган документлар (документлар төп нөсхәдә (документлар һәркем файдалана алырлык булса, күчермәләрдә) яисә җир участогына хокук алу турында гариза кабул итүче башкарма хакимият органының яки җирле үзидарә органының вазыйфаи заты тарафыннан таныклана торган күчермәләрдә) тапшырыла (җибәрелә) |
|---|---|---|---|---|---|
| 1. | Россия Федерациясе Җир кодексының (алга таба – Җир кодексы) 39.3 статьясындагы 2 пунктының 3 пунктчасы | Түләү нигезендә милеккә | Коммерцияле булмаган бакчачылык ширкәте (СНТ) яки коммерцияле булмаган яшелчәчелек ширкәте (ОНТ) әгъзасы | СНТ яки ОНТ тарафыннан бирелгән җир участогыннан төзелгән бакчачылык җир участогы яки яшелчәчелек җир участогы | * Башлангыч җир участогына хокук Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрында теркәлгән очраклардан тыш, СНТ яки ОНТ җир участогын бирү турында документ<br><br>Гариза бирүченең СНТ яки ОНТ әгъзасы булуны раслаучы документ<br><br>СНТ яки ОНТ әгъзаларының гомуми җыелышы карары яки ул гариза бирүчегә бакчачылык яки яшелчәчелек җир участогын бүлү турында<br><br>* Территорияне межалауның расланган проекты<br><br>* Күчемсез милек объекты турында (сорала торган җир участогы турында) Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрыннан өземтә<br><br>*СНТ һәм ОНТ га карата Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрыннан өземтә |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 2. | Җир кодексының 39.3 статьясындагы 2 пунктының 6 пунктчасы | Түләү нигезендә милеккә | Бина, корылмалар яисә бинадагы, корылмадагы бүлмә милекчесе | Бина, корылма урнашкан җир участогы | Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрында гариза бирүченең бинага, корылмага яки бүлмәгә хокукын раслаучы (билгеләүче) документ<br><br>Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрында (җир участогына тиешле хокуклар булганда) мондый җир участогында хокук теркәлмәгән очракта, гариза бирүченең сорала торган җир участогына хокукын раслаучы (билгеләүче) документ<br><br>Гариза бирүченең (гариза бирүчеләрнең) сорала торган җир участогында урнашкан барлык биналар, корылмалар исемлеге, кадастр (шартлы, инвентарь) номерлары һәм гариза бирүчегә тиешле хокукта карый торган биналарның, корылмаларның адреслы ориентирлары күрсәтелгән хәбәре<br><br>* Күчемсез милек объекты турында (сорала торган җир участогы турында) Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрыннан өземтә<br><br>* Күчемсез милек объекты (сорала торган җир участогында урнашкан бина һәм (яки) корылма турында) Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрынnannан өземтә<br><br>* күчемсез милек объекты (бина милекчесе мөрәҗәгать иткән очракта, сорала торган җир участогында урнашкан бина, корылма турында) Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрыннаннан өземтә<br>* Гариза бирүче булып торган юридик зат турында Бердәм дәүләт юридик затлар реестрыннан өземтә<br><br>* Гариза бирүче булып торган шәхси эшмәкәр турында Бердәм дәүләт шәхси эшмәкәрләр реестрыннан өземтә |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 3. | Җир кодексының 39.3 статьясындагы 2 пунктының 7 пунктчасы | Түләү нигезендә милеккә | Җир участгын даими (сроксыз) файдалану хокукында файдаланучы юридик зат | Даими (сроксыз) файдалану хокукында юридик затка караган җир участогы | Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрында мондый җир участогына хокук теркәлмәгән булса, гариза бирүченең сорала торган җир участогына хокукын раслаучы (билгеләүче) документлар<br><br>* Күчемсез милек объекты турында (сорала торган җир участогы турында) Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрыннан өземтә<br><br>* Гариза бирүче булып торган юридик зат турында Бердәм дәүләт юридик затлар реестрыннан өземтә |
| 4. | Җир кодексының 39.3 статьясындагы 2 пунктының 8 пунктчасы | Түләү нигезендә милеккә | Муниципаль милектә булган һәм муниципаль милектәге җир участоклары исәбенә бүлеп бирелгән җир участогыннан файдаланучы крестьян (фермер) хуҗалыгы яки авыл хуҗалыгы оешмасы | Муниципаль милектә булган һәм муниципаль милектәге җир участоклары исәбенә бүлеп бирелгән җир участогы | * Күчемсез милек объекты турында (сорала торган җир участогы турында) Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрыннан өземтә<br><br>* Гариза бирүче булып торган юридик зат турында Бердәм дәүләт юридик затлар реестрыннан өземтә<br><br>* Гариза бирүче булып торган шәхси эшмәкәр турында Бердәм дәүләт шәхси эшмәкәрләр реестрыннан өземтә |
| 5. | Җир кодексының 39.3 статьясындагы 2 пунктының 9 пунктчасы | Түләү нигезендә милеккә | Авыл хуҗалыгы производствосын алып бару өчен билгеләнгән җир участогын арендалаучылар булып торучы граждан яки юридик зат | Авыл хуҗалыгы производствосын алып бару өчен билгеләнгән һәм аренда шартнамәсе нигезендә өч елдан артык файдаланыла торган җир участогы | * Күчемсез милек объекты турында (сорала торган җир участогы турында) Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрыннан өземтә<br><br>* Гариза бирүче булып торган юридик зат турында Бердәм дәүләт юридик затлар реестрыннан өземтә<br><br>* Гариза бирүче булып торган шәхси эшмәкәр турында Бердәм дәүләт шәхси эшмәкәрләр реестрыннан өземтә |
| 6. | Җир кодексының 39.3 статьясындагы 2 пунктының 10 пунктчасы | Түләү нигезендә милеккә | Торак пункт, бакчачылык чикләрендә индивидуаль торак төзелеше, шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен җир участогы бирү турында һәм җир участогы бирүне алдан килештерү турында гариза биргән граждан | Индивидуаль торак төзелеше, торак пункт, бакчачылык чикләрендә шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен билгеләнгән җир участогы | * Күчемсез милек объекты турында (сорала торган җир участогы турында) Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрыннан өземтә |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 7. | Җир кодексының 39.6 статьясындагы 2 пунктның 1 пунктчасы | Арендага | Юридик зат | Россия Федерациясе Президенты Указы яки боерыгы нигезендә билгеләнә | * Россия Федерациясе Президенты Указы яки боерыгы<br><br>* Күчемсез милек объекты турында (сорала торган җир участогы турында) Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрыннан өземтә<br><br>* Гариза бирүче булып торган юридик зат турында Бердәм дәүләт юридик затлар реестрыннан өземтә |
| 8. | Җир кодексының 39.6 статьясындагы 2 пунктның 2 пунктчасы | Арендага | Юридик зат | Социаль-мәдәни билгеләнештәге объектларны урнаштыру, масштаблы инвестиция проектларын тормышка ашыру өчен билгеләнгән җир участогы | * Россия Федерациясе Хөкүмәте Боерыгы<br><br>* Күчемсез милек объекты турында (сорала торган җир участогы турында) Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрыннан өземтә<br><br>* Гариза бирүче булып торган юридик зат турында Бердәм дәүләт юридик затлар реестрыннан өземтә |
| 9. | Җир кодексының 39.6 статьясындагы 2 пунктның 3 пунктчасы | Арендага | Юридик зат | Социаль-мәдәни һәм коммуналь-көнкүреш билгеләнешендәге объектларны урнаштыру, масштаблы инвестиция проектларын тормышка ашыру өчен билгеләнгән җир участогы | * Россия Федерациясе субъектының югары вазыйфаи заты боерыгы<br><br>* Күчемсез милек объекты турында (сорала торган җир участогы турында) Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрыннан өземтә<br><br>* Гариза бирүче булып торган юридик зат турында Бердәм дәүләт юридик затлар реестрыннан өземтә |
| 10. | Җир кодексының 39.6 статьясындагы 2 пунктның 4 пунктчасы | Арендага | Юридик зат | Халыкара йөкләмәләрне үтәү өчен билгеләнгән җир участогы | Шартнамә, килешү яки халыкара йөкләмәләрне үтәүне күздә тоткан башка документ |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 11. | Җир кодексының 39.6 статьясындагы 2 пунктның 4 пунктчасы | Арендага | Юридик зат | Электр, җылылык, газ һәм су белән тәэмин итү, су бүлү, элемтә, нефть үткәргечләр белән тәмин итү өчен билгеләнгән объектларны, федераль, региональ яки җирле әһәмияткә ия объектларны урнаштыру өчен билгеләнгән җир участогы | * Территориаль планлаштыру документыннан өземтә яки территорияне планлаштыру документларыннан объектның федераль, региональ яки җирле әһәмияткә ия объектларга каравын раслый торган өземтә (электр, җылылык, газ һәм су белән тәэмин итү, су бүлү, элемтә, нефть үткәргечләр белән тәмин итү өчен билгеләнгән, федераль, региональ яки җирле әһәмияткә ия объектларга карамаган объектларны урнаштырган очракта таләп ителми)<br>* Күчемсез милек объекты турында (сорала торган җир участогы турында) Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрыннан өземтә<br>* Гариза бирүче булып торган юридик зат турында Бердәм дәүләт юридик затлар реестрыннан өземтә |
| 12. | Җир кодексының 39.6 статьясындагы 2 пунктның 5 пунктчасы | Арендага | Сорала торган җир участогы барлыкка килгән, дәүләт яки муниципаль милектәге җир участогы арендаторы | Дәүләт яки муниципаль милектәге җир участогыннан барлыкка килгән җир участогы | Мондый шартнамә «Күчемсез милеккә хокукларны һәм аның белән килешүләр төзүне дәүләт теркәвенә алу турында» 1997 елның 21 июлендәге 122-ФЗ номерлы Федераль закон үз көченә кергән көнгә кадәр төзелгән булган очракта, башлангыч җир участогын арендалау шартнамәсе <23><br>* Күчемсез милек объекты турында (сорала торган җир участогы турында) Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрыннан өземтә<br>* Гариза бирүче булып торган юридик зат турында Бердәм дәүләт юридик затлар реестрыннан өземтә |
| 13. | Җир кодексының 39.6 статьясындагы 2 пунктның 5 пунктчасы | Арендага | Сорала торган җир участогы барлыкка килгән, территорияне комплекслы үзләштерү өчен бирелгән җир участогы арендаторы | Территорияне комплекслы үзләштерү өчен мондый җир участогын арендалау шартнамәсе төзелгән затка бирелгән, дәүләт яки муниципаль милектәге җир участогыннан барлыкка килгән җир участогы | Территорияне комплекслы үзләштерү турында шартнамә<br>* Планлаштыруның расланган проекты һәм территорияне межалауның расланган проекты<br>* Күчемсез милек объекты турында (сорала торган җир участогы турында) Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрыннан өземтә<br>* Гариза бирүче булып торган юридик зат турында Бердәм дәүләт юридик затлар реестрыннан өземтә |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 14. | Җир кодексының 39.6 статьясындагы 2 пунктның 7 пунктчасы | Арендага | Коммерцияле булмаган бакчачылык ширкәте яки коммерцияле булмаган яшелчәчелек ширкәте әгъзасы | Коммерцияле булмаган бакчачылык ширкәтенә яки коммерцияле булмаган яшелчәчелек ширкәтенә бирелгән җир участогыннан барлыкка килгән бакча җир участогы яки яшелчә җир участогы | * Башлангыч җир участогын коммерцияле булмаган бакчачылык ширкәтенә яки коммерцияле булмаган яшелчәчелек ширкәтенә бирү турында документ, башлангыч җир участогына хокук Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрында теркәлгән очраклардан тыш<br><br>Гариза бирүченең коммерцияле булмаган бакчачылык ширкәте яки коммерцияле булмаган яшелчәчелек ширкәте әгъзалыгын раслаучы документ<br><br>Коммерцияле булмаган бакчачылык ширкәте яки коммерцияле булмаган яшелчәчелек ширкәте әгъзалары гомуми җыелышының бакча яки яшелчә җир участогын гариза бирүчегә бүлеп бирү турында карары<br><br>* Территорияне межалауның расланган проекты<br><br>* Күчемсез милек объекты турында (сорала торган җир участогы турында) Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрыннан өземтә<br><br>* Коммерцияле булмаган бакчачылык ширкәтенә яки коммерцияле булмаган яшелчәчелек ширкәтенә карата Бердәм дәүләт юридик затлар реестрыннан өземтә |
| 15. | Җир кодексының 39.6 статьясындагы 2 пунктның 8 пунктчасы | Арендатор ягында күп санлы затлар белән арендага | Коммерцияле булмаган бакчачылык ширкәте яки коммерцияле булмаган яшелчәчелек ширкәте әгъзаларының гомуми җыелышы карары белән гариза бирүгә вәкаләтләнгән зат | Әйләнештә чикләнгән, бакчачылык яки яшелчәчелек территориясе чикләрендә урнашкан гомуми билгеләнештәге җир участогы | * Башлангыч җир участогын коммерцияле булмаган бакчачылык ширкәтенә яки коммерцияле булмаган яшелчәчелек ширкәтенә бирү турында документ, башлангыч җир участогына хокук Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрында теркәлгән очраклардан тыш<br><br>* Коммерцияле булмаган бакчачылык ширкәте яки коммерцияле булмаган яшелчәчелек ширкәте әгъзалары гомуми җыелышының бакчачылык яки яшелчәчелек территориясе чикләрендә урнашкан гомуми билгеләнештәге җир участогын арендалау хокукын сатып алу турында карары<br>* Территорияне межалауның расланган проекты |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | * Күчемсез милек объекты турында (сорала торган җир участогы турында) Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрыннан өземтә<br><br>* Коммерцияле булмаган бакчачылык ширкәтенә яки коммерцияле булмаган яшелчәчелек ширкәтенә карата Бердәм дәүләт юридик затлар реестрыннан өземтә |
| 16. | Җир кодексының 39.6 статьясындагы 2 пунктның 9 пунктчасы | Арендага | Бина, корылма, алардагы бүлмәләр милекчесе һәм (яки) әлеге күчемсез милек объектлары хуҗалык алып бару хокукында яки Җир кодексының 39.20 статьясында каралган очракларда оператив идарә хокукында бирелгән зат | Биналар, корылмалар урнашкан җир участогы | Мондый бинага, корылмага хокук Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрында теркәлмәгән очракта, гариза бирүченең бинага, корылмага хокукын раслаучы (билгеләүче) документлар<br><br>Гариза бирүченең сорала торган җир участогына хокукын раслаучы (билгеләүче) документлар, әгәр мондый җир участогына хокук Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрында теркәлмәгән булса (җир участогына тиешле хокуклар булганда)<br><br>Гариза бирүченең (гариза бирүчеләрнең) сорала торган җир участогында урнашкан барлык биналар, корылмалар исемлеген үз эченә алган, тиешле хокукта гариза бирүчегә караган биналарның, корылмаларның кадастр (шартлы, инвентарь) номерлары һәм адрес ориентирлары күрсәтелгән хәбәре<br><br>* Күчемсез милек объекты турында (сорала торган җир участогы турында) Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрыннан өземтә<br><br>* Күчемсез милек объекты турында (сорала торган җир участогында урнашкан бина һәм (яки) корылма турында) Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрыннан өземтә<br><br>* Гариза бирүче булып торган юридик зат турында Бердәм дәүләт юридик затлар реестрыннан өземтә<br><br>* Күчемсез милек объекты турында (бүлмә милекчесе мөрәҗәгать иткән очракта, сорала торган җир участогында |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | урнашкан бинадагы, корылмадагы бүлмә турында) Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрыннан өземтә |
| 17. | Җир кодексының 39.6 статьясындагы 2 пунктның 10 пунктчасы, «Россия Федерациясе Җир кодексын гамәлгә кертү турында» 2001 елның 25 октябрендәге 137-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясындагы 21 пункты | Арендага | Төзелеше тәмамланмаган объект милекчесе | Төзелеше тәмамланмаган объект урнашкан җир участогы | Төзелеше тәмамланмаган мондый объектка хокук Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрында теркәлмәгән очракта, гариза бирүченең төзелеше тәмамланмаган объектка хокукын раслаучы (билгеләүче) документлар<br><br>Гариза бирүченең сорала торган җир участогына хокукын раслаучы (билгеләүче) документлар, әгәр мондый җир участогына хокук Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрында теркәлмәгән булса (җир участогына тиешле хокуклар булганда)<br><br>Гариза бирүченең (гариза бирүчеләрнең) сорала торган җир участогында урнашкан барлык биналар, корылмалар, төзелеше тәмамланмаган объектлар исемлеген үз эченә алган, тиешле хокукта гариза бирүчегә караган биналарның, корылмаларның, төзелеше тәмамланмаган объектларның кадастр (шартлы, инвентарь) номерлары һәм адрес ориентирлары күрсәтелгән хәбәре<br><br>* Күчемсез милек объекты турында (сорала торган җир участогы турында) Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрыннан өземтә<br><br>* Сорала торган җир участогында урнашкан күчемсез милек объекты (төзелеше тәмамланмаган объект турында) Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрыннан өземтә<br><br>* Гариза бирүче булып торган юридик зат турында Бердәм дәүләт юридик затлар реестрыннан өземтә |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 18. | Җир кодексының 39.6 статьясындагы 2 пунктның 11 пунктчасы | Арендага | Җир участогыннан даими (сроксыз) файдалану хокукында файдаланучы юридик зат | Даими (сроксыз) файдалану хокукында юридик затка караган җир участогы | Гариза бирүченең сорала торган җир участогына хокукын раслаучы (билгеләүче) документлар, әгәр мондый җир участогына хокук Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрында теркәлмәгән булса<br><br>* Күчемсез милек объекты турында (сорала торган җир участогы турында) Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрыннан өземтә<br><br>* Гариза бирүче булып торган юридик зат турында Бердәм дәүләт юридик затлар реестрыннан өземтә |
| 19. | Җир кодексының 39.6 статьясындагы 2 пунктның 12 пунктчасы | Арендага | Крестьян (фермер) хуҗалыгы яки муниципаль милектә булган һәм муниципаль милектәге җир өлешләре исәбенә бүлеп бирелгән җир участогыннан файдаланучы авыл хуҗалыгы оешмасы | Муниципаль милектә булган һәм муниципаль милектәге җир участоклары исәбенә бүлеп бирелгән җир участогы | * Күчемсез милек объекты турында (сорала торган җир участогы турында) Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрыннан өземтә<br><br>* Гариза бирүче булып торган юридик зат турында Бердәм дәүләт юридик затлар реестрыннан өземтә<br><br>* Гариза бирүче булып торган шәхси эшмәкәр турында Бердәм дәүләт шәхси эшмәкәрләр реестрыннан өземтә |
| 20. | Җир кодексының 39.6 статьясындагы 2 пунктның 13 пунктчасы | Арендага | Төзелгән территорияне үстерү турында шартнамә төзелгән зат | Төзелгән территория (аңа карата аны үстерү турында шартнамә төзелгән) чикләрендә барлыкка килгән җир участогы | Төзелгән территорияне үстерү турында шартнамә<br><br>* Күчемсез милек объекты турында (сорала торган җир участогы турында) Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрыннан өземтә<br><br>* Планлаштыруның расланган проекты һәм территорияне межалауның расланган проекты<br><br>* Гариза бирүче булып торган юридик зат турында Бердәм дәүләт юридик затлар реестрыннан өземтә |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 21. | Җир кодексының 39.6 статьясындагы 2 пунктның 14 пунктчасы | Арендага | Җир участокларын беренче чиратта яки чираттан тыш алу хокукына ия граждан | Җир участокларын бирү очраклары федераль закон яисә Россия Федерациясе субъекты законы белән билгеләнә | Вәкаләтле орган тарафыннан бирелгән, гражданның җир участокларын беренче чиратта яки чиратсыз алу хокукына ия гражданнар категориясенә каравын раслаучы документ<br><br>*Күчемсез милек объекты турында (сорала торган җир участогы турында) Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрыннан өземтә |
| 22. | Җир кодексының 39.6 статьясындагы 2 пунктның 15 пунктчасы | Арендага | Җир участогы бирүне алдан килештерү турында яки торак пункт, бакчачылык чикләрендә индивидуаль торак төзелеше, шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен җир участогы бирү турында гариза биргән граждан | Торак пункт, бакчачылык чикләрендә индивидуаль торак төзелеше, шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен билгеләнгән җир участогы | Җир участогы бирүне алдан килештерү турында карар<br><br>*Күчемсез милек объекты турында (сорала торган җир участогы турында) Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрыннан өземтә |
| 23. | Җир кодексының 39.6 статьясындагы 2 пунктның 16 пунктчасы | Арендага | Аренда хокукында бирелгән җир участогы дәүләт яки муниципаль ихтыяҗлар өчен алынган граждан яки юридик зат | Гражданга яки юридик затка аренда хокукында бирелгән һәм дәүләт яки муниципаль ихтыяҗлар өчен алына торган җир участогына алмашка бирелә торган җир участогы | Дәүләт яки муниципаль ихтыяҗлар өчен җир участогын алу турында килешү яки җир участогын дәүләт яки муниципаль ихтыяҗлар өчен алуга нигез булган суд карары<br><br>* Күчемсез милек объекты турында (сорала торган җир участогы турында) Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрыннан өземтә<br>* Гариза бирүче булып торган юридик зат турында Бердәм дәүләт юридик затлар реестрыннан өземтә |
| 24. | Җир кодексының 39.6 статьясындагы 2 пунктның 17 пунктчасы | Арендага | Дини оешма | Авыл хуҗалыгы производствосын гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән җир участогы | * Күчемсез милек объекты турында (сорала торган җир участогы турында) Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрыннан өземтә<br><br>* Гариза бирүче булып торган юридик зат турында Бердәм дәүләт юридик затлар реестрыннан өземтә |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 25. | Җир кодексының 39.6 статьясындагы 2 пунктның 17 пунктчасы | Арендага | Казак җәмгыяте | Авыл хуҗалыгы производствосын гамәлгә ашыру, казак җәмгыятьләренең традицион яшәү һәм хуҗалык итү рәвешен саклау һәм үстерү өчен билгеләнгән җир участогы | Казак җәмгыятен Россия Федерациясендә дәүләт казак җәмгыятьләре реестрына кертү турында таныклык<br><br>* Күчемсез милек объекты турында (сорала торган җир участогы турында) Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрыннан өземтә<br><br>* Гариза бирүче булып торган юридик зат турында Бердәм дәүләт юридик затлар реестрыннан өземтә |
| 26. | Җир кодексының 39.6 статьясындагы 2 пунктның 18 пунктчасы | Арендага | Дәүләт яки муниципаль милектәге җир участогын сатулар үткәрмичә милеккә алу хокукына ия зат, шул исәптән бушлай | Әйләнештә чикләнгән җир участогы | Әлеге исемлектә каралган һәм гариза бирүченең җир участогын сатулар үткәрмичә милеккә бирү хокукын раслый торган документ<br><br>* Күчемсез милек объекты турында (сорала торган җир участогы турында) Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрыннан өземтә<br><br>* Гариза бирүче булып торган юридик зат турында Бердәм дәүләт юридик затлар реестрыннан өземтә |
| 27. | Җир кодексының 39.6 статьясындагы 2 пунктның 19 пунктчасы | Арендага | Печән чабу, авыл хуҗалыгы терлекләрен көтү, яшелчәчелек алып бару өчен җир участогы яки шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен торак пункт чикләреннән читтә урнашкан җир участогы сораучы граждан | Печән чабу, авыл хуҗалыгы терлекләрен көтү, яшелчәчелек алып бару өчен билгеләнгән җир участогы яки шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен торак пункт чикләреннән читтә урнашкан җир участогы | * Күчемсез милек объекты турында (сорала торган җир участогы турында) Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрыннан өземтә |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 28. | Җир кодексының 39.6 статьясындагы 2 пунктның 20 пунктчасы | Арендага | Җир асты байлыкларыннан файдаланучы | Җир асты байлыкларыннан файдалану белән бәйле эшләр башкару өчен кирәкле җир участогы | Җир асты байлыкларыннан файдалану белән бәйле эшләр башкаруга проект документлары, җир асты байлыкларын дәүләти геологик өйрәнү чараларын үтәүне күздә тоткан дәүләт йөкләмәсе яки тиешле эшчәнлекне гамәлгә ашыруны күздә тота торган, җир асты байлыкларын яисә аларның өлешләрен геологик өйрәнү (шул исәптән региональ) буенча эшләр башкаруга дәүләт контракты (дәүләт серен тәшкил иткән мәгълүматлардан тыш)<br><br>* Күчемсез милек объекты турында (сорала торган җир участогы турында) Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрыннан өземтә<br><br>* Гариза бирүче булып торган юридик зат турында Бердәм дәүләт юридик затлар реестрыннан өземтә |
| 29. | Җир кодексының 39.6 статьясындагы 2 пунктның 21 пунктчасы | Арендага | Махсус икътисадый зона резиденты | Махсус икътисадый зона чикләрендә яки аның янәшәсендәге территориядә урнашкан җир участогы | Махсус икътисадый зона резиденты буларак теркәлүне раслаучы таныклык<br><br>* Күчемсез милек объекты турында (сорала торган җир участогы турында) Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрыннан өземтә<br><br>* Гариза бирүче булып торган юридик зат турында Бердәм дәүләт юридик затлар реестрыннан өземтә |
| 30. | Җир кодексының 39.6 статьясындагы 2 пунктның 21 пунктчасы | Арендага | Федераль бюджет, Россия Федерациясе субъекты бюджеты, җирле бюджет, махсус икътисадый зона чикләрендә һәм аның янәшәсендәге территориядә күчемсез милек объектларын | Махсус икътисадый зона чикләрендә яки аның янәшәсендәге территориядә урнашкан җир участогы | Махсус икътисадый зона белән идарә итү турында килешү<br><br>* Күчемсез милек объекты турында (сорала торган җир участогы турында) Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрыннан өземтә |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | финанслауның бюджеттан тыш чыганаклары һәм әлеге һәм элек төзелгән күчемсез милек объектлары белән идарә итү функцияләрен үтәү өчен җәлеп ителгән идарәче компания | | * Гариза бирүче булып торган юридик зат турында Бердәм дәүләт юридик затлар реестрыннан өземтә |
| 31. | Җир кодексының 39.6 статьясындагы 2 пунктның 22 пунктчасы | Арендага | Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан вәкаләтләнгән федераль башкарма хакимият органы белән махсус икътисадый зона инфраструктурасын үстерү өлкәсендә хезмәттәшлек турында килешү төзелгән зат | Әлеге зона инфраструктурасы объектларын төзү өчен билгеләнгән, махсус икътисадый зона чикләрендә яки аның янәшәсендәге территориядә урнашкан җир участогы | Махсус икътисадый зона инфраструктурасын үстерү өлкәсендә хезмәттәшлек турында килешү<br><br>* Күчемсез милек объекты турында (сорала торган җир участогы турында) Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрыннан өземтә<br><br>* Гариза бирүче булып торган юридик зат турында Бердәм дәүләт юридик затлар реестрыннан өземтә |
| 32. | Җир кодексының 39.6 статьясындагы 2 пунктның 23 пунктчасы | Арендага | Концессион килешү төзелгән зат | Концессион килешүдә каралган эшчәнлекне гамәлгә ашыру өчен кирәкле җир участогы | Концессион килешү<br><br>* Күчемсез милек объекты турында (сорала торган җир участогы турында) Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрыннан өземтә<br><br>* Гариза бирүче булып торган юридик зат турында Бердәм дәүләт юридик затлар реестрыннан өземтә |
| 33. | Җир кодексының 39.6 статьясындагы 2 пунктның 23.1 пунктчасы | Арендага | Коммерцияле файдаланудагы наемга алынган йортны төзү һәм эксплуатацияләү максатларында территорияне үзләштерү турында шартнамә төзегән зат | Коммерцияле файдаланудагы наемга алынган йортны төзү һәм эксплуатацияләү максатларында территорияне үзләштерү өчен билгеләнгән җир участогы | Коммерцияле файдаланудагы наемга алынган йортны төзү һәм эксплуатацияләү максатларында территорияне үзләштерү турында шартнамә<br><br>* Планлаштыруның расланган проекты һәм территорияне межалауның расланган проекты<br><br>* Күчемсез милек объекты турында (сорала торган җир участогы турында) Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрыннан өземтә |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | * Гариза бирүче булып торган юридик зат турында Бердәм дәүләт юридик затлар реестрыннан өземтә |
| 34. | Җир кодексының 39.6 статьясындагы 2 пунктның 23.1 пунктчасы | Арендага | Социаль файдаланудагы наемга алынган йортны төзү һәм эксплуатацияләү максатларында территорияне үзләштерү турында шартнамә төзегән юридик зат | Социаль файдаланудагы наемга алынган йортны төзү һәм эксплуатацияләү максатларында территорияне үзләштерү өчен билгеләнгән җир участогы | Социаль файдаланудагы наемга алынган йортны төзү һәм эксплуатацияләү максатларында территорияне үзләштерү турында шартнамә<br><br>* Планлаштыруның расланган проекты һәм территорияне межалауның расланган проекты<br>* Күчемсез милек объекты турында (сорала торган җир участогы турында) Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрыннан өземтә<br><br>* Гариза бирүче булып торган юридик зат турында Бердәм дәүләт юридик затлар реестрыннан өземтә |
| 35. | Җир кодексының 39.6 статьясындагы 2 пунктның 23.2 пунктчасы | Арендага | Махсус инвестиция контракты төзелгән юридик зат | Махсус инвестиция контрактында каралган эшчәнлекне гамәлгә ашыру өчен кирәкле җир участогы | Махсус инвестиция контракты<br><br>* Күчемсез милек объекты турында (сорала торган җир участогы турында) Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрыннан өземтә<br><br>* Гариза бирүче булып торган юридик зат турында Бердәм дәүләт юридик затлар реестрыннан өземтә |
| 36. | Җир кодексының 39.6 статьясындагы 2 пунктның 24 пунктчасы | Арендага | Аучылык хуҗалыгы килешүе төзелгән зат | Аучылык хуҗалыгы өлкәсендә эшчәнлек төрләрен гамәлгә ашыру өчен кирәкле җир участогы | Аучылык хуҗалыгы килешүе<br><br>* Күчемсез милек объекты турында (сорала торган җир участогы турында) Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрыннан өземтә<br><br>* Гариза бирүче булып торган юридик зат турында Бердәм дәүләт юридик затлар реестрыннан өземтә<br><br>* Гариза бирүче булып торган шәхси эшмәкәр турында Бердәм дәүләт шәхси эшмәкәрләр реестрыннан өземтә |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 37. | Җир кодексының 39.6 статьясындагы 2 пунктның 25 пунктчасы | Арендага | Сусаклагыч һәм (яки) гидротехник корылма урнаштыру өчен җир участогы сораучы зат | Сусаклагыч һәм (яки) гидротехник корылма урнаштыру өчен билгеләнгән җир участогы | * Күчемсез милек объекты турында (сорала торган җир участогы турында) Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрыннан өземтә<br><br>* Гариза бирүче булып торган юридик зат турында Бердәм дәүләт юридик затлар реестрыннан өземтә<br><br>* Гариза бирүче булып торган шәхси эшмәкәр турында Бердәм дәүләт шәхси эшмәкәрләр реестрыннан өземтә |
| 38. | Җир кодексының 39.6 статьясындагы 2 пунктның 26 пунктчасы | Арендага | «Россия автомобиль юллары» дәүләт компаниясе | «Россия автомобиль юллары» дәүләт компаниясе эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен кирәкле, автомобиль юлы өчен бүлеп бирелгән полоса һәм юл буе полосасы чикләрендә урнашкан җир участогы | * Күчемсез милек объекты турында (сорала торган җир участогы турында) Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрыннан өземтә<br><br>* Гариза бирүче булып торган юридик зат турында Бердәм дәүләт юридик затлар реестрыннан өземтә |
| 39. | Җир кодексының 39.6 статьясындагы 2 пунктның 27 пунктчасы | Арендага | «Россия тимер юллары» ачык акционерлык җәмгыяте | Гомуми файдаланудагы тимер юл транспорты инфраструктурасы объектларын урнаштыру өчен билгеләнгән «Россия тимер юллары» ачык акционерлык җәмгыяте эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен кирәкле җир участогы | * Күчемсез милек объекты турында (сорала торган җир участогы турында) Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрыннан өземтә<br><br>* Гариза бирүче булып торган юридик зат турында Бердәм дәүләт юридик затлар реестрыннан өземтә |
| 40. | Җир кодексының 39.6 статьясындагы 2 пунктның 28 пунктчасы | Арендага | Территориаль үсеш зонасы резидентлары реестрына кертелгән территориаль үсеш зонасы резиденты | Территориаль үсеш зонасы чикләрендә җир участогы | Составында инвестицион проект тәкъдим ителгән инвестиция декларациясе<br><br>* Күчемсез милек объекты турында (сорала торган җир участогы турында) Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрыннан өземтә<br><br>* Гариза бирүче булып торган юридик зат турында Бердәм дәүләт юридик затлар реестрыннан өземтә |
| 41. | Җир кодексының 39.6 статьясындагы | Арендага | Биологик су ресурсларын табу (тоту) хокукына ия зат | Биологик су ресурсларын файдалануга бирү турында карарда, балык промыселы | * Биологик су ресурсларын файдалануга бирү турында карар, яисә балык промыселы участогы бирү турында шартнамә, яисә биологик су ресурсларыннан файдалану шартнамәсе |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | 2 пунктның 29 пунктчасы | | | участогы бирү турында шартнамәдә, биологик су ресурсларыннан файдалану шартнамәсендә каралган эшчәнлекне гамәлгә ашыру өчен кирәкле җир участогы | * Кучемсез милек объекты турында (сорала торган җир участогы турында) Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрыннан өземтә<br><br>* Гариза бирүче булып торган юридик зат турында Бердәм дәүләт юридик затлар реестрыннан өземтә |
| 42. | Җир кодексының 39.6 статьясындагы 2 пунктның 29.1 пунктчасы | Арендага | Товар аквакультурасын (товар балыгы үрчетүне) гамәлгә ашыручы зат | Товар аквакультурасын (товар балыгы үрчетүне) гамәлгә ашыру өчен, дәүләт яисә муниципаль милектәге балык үрчетү участогыннан файдалану шартнамәсендә каралган эшчәнлекне гамәлгә ашыру өчен кирәкле җир участогы | * Балык үрчетү участогыннан файдалану шартнамәсе<br><br>* Күчемсез милек объекты турында (сорала торган җир участогы турында) Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрыннан өземтә<br><br>* Гариза бирүче булып торган юридик зат турында Бердәм дәүләт юридик затлар реестрыннан өземтә<br>* Гариза бирүче булып торган шәхси эшмәкәр турында Бердәм дәүләт шәхси эшмәкәрләр реестрыннан өземтә |
| 43. | Җир кодексының 39.6 статьясындагы 2 пунктның 30 пунктчасы | Арендага | Атом-төш җайланмаларын, радиация чыганакларын, атом-төш материалларын һәм радиоактив матдәләрне саклау пунктларын, радиоактив калдыкларны саклагычларны, саклау пунктларын һәм радиоактив калдыкларны күмү пунктларын урнаштыруны гамәлгә ашыручы юридик зат | Атом-төш җайланмаларын, радиация чыганакларын, атом-төш материалларын һәм радиоактив матдәләрне саклау пунктларын, радиоактив калдыкларны саклагычларны, саклау пунктларын һәм радиоактив калдыкларны күмү пунктларын урнаштыру өчен билгеләнгән җир участогы | * Атом-төш җайланмаларын, радиация чыганакларын, атом-төш материалларын һәм радиоактив матдәләрне саклау пунктларын, радиоактив калдыкларны саклагычларны, саклау пунктларын һәм радиоактив калдыкларны күмү пунктларын төзү һәм аларны урнаштыру урыны турында Россия Федерациясе Хөкүмәте карары<br><br>* Күчемсез милек объекты турында (сорала торган җир участогы турында) Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрыннан өземтә<br><br>* Гариза бирүче булып торган юридик зат турында Бердәм дәүләт юридик затлар реестрыннан өземтә |
| 44. | Җир кодексының 39.6 статьясындагы 2 пунктның 31 пунктчасы | Арендага | Авыл хуҗалыгы производствосын алып бару өчен билгеләнгән җир участогын арендалаучы граждан яки юридик зат | Авыл хуҗалыгы производствосын алып бару өчен билгеләнгән һәм аренда шартнамәсе нигезендә файдаланыла торган җир участогы | * Күчемсез милек объекты турында (сорала торган җир участогы турында) Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрыннан өземтә<br><br>* Гариза бирүче булып торган юридик зат турында Бердәм дәүләт юридик затлар реестрыннан өземтә |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | * Гариза бирүче булып торган шәхси эшмәкәр турында Бердәм дәүләт шәхси эшмәкәрләр реестрыннан өземтә |
| 45. | Җир кодексының 39.6 статьясындагы 2 пунктның 32 пунктчасы | Арендага | Җир участогын арендалау буенча яңа шартнамә төзү хокукына ия җир участогы арендаторы | Аренда шартнамәсе нигезендә файдаланыла торган җир участогы | Гариза бирүченең сорала торган җир участогына хокукын раслаучы (билгеләүче) документлар, әгәр мондый җир участогына хокук Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрында теркәлмәгән булса<br><br>* Күчемсез милек объекты турында (сорала торган җир участогы турында) Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрыннан өземтә<br><br>* Гариза бирүче булып торган юридик зат турында Бердәм дәүләт юридик затлар реестрыннан өземтә |
| 46. | Җир кодексының 39.9 статьясындагы 2 пунктның 1 пунктчасы | Даими (сроксыз) файдалануга | Дәүләт хакимияте органы | Дәүләт хакимияте органнары тарафыннан үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен кирәкле җир участогы | Җир участогыннан файдалану максатлары нигезендә җир участогы бирүгә гариза бирүченең хокукын раслый торган, әлеге исемлек белән каралган документлар<br><br>* Күчемсез милек объекты турында (сорала торган җир участогы турында) Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрыннан өземтә |
| 47. | Җир кодексының 39.9 статьясындагы 2 пунктның 1 пунктчасы | Даими (сроксыз) файдалануга | Җирле үзидарә органы | Җирле үзидарә органнары тарафыннан үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен кирәкле җир участогы | Җир участогыннан файдалану максатлары нигезендә җир участогы бирүгә гариза бирүченең хокукын раслый торган, әлеге исемлек белән каралган документлар<br><br>* Күчемсез милек объекты турында (сорала торган җир участогы турында) Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрыннан өземтә |
| 48. | Җир кодексының 39.9 статьясындагы 2 пунктның 2 пунктчасы | Даими (сроксыз) файдалануга | Дәүләт яки муниципаль учреждение (бюджет, казна, автоном) | Дәүләт яки муниципаль учреждение (бюджет, казна, автоном) эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен кирәкле җир участогы | Җир участогыннан файдалану максатлары нигезендә җир участогы бирүгә гариза бирүченең хокукын раслый торган, әлеге исемлек белән каралган документлар<br><br>* Күчемсез милек объекты турында (сорала торган җир участогы турында) Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрыннан өземтә<br><br>* Гариза бирүче булып торган юридик зат турында Бердәм |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | дәүләт юридик затлар реестрыннан өземтә |
| 49. | Җир кодексының 39.9 статьясындагы 2 пунктның 3 пунктчасы | Даими (сроксыз) файдалануга | Казна предприятиесе | Казна предприятиесе эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен кирәкле җир участогы | Җир участогыннан файдалану максатлары нигезендә җир участогы бирүгә гариза бирүченең хокукын раслый торган, әлеге исемлек белән каралган документлар<br><br>* Күчемсез милек объекты турында (сорала торган җир участогы турында) Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрыннан өземтә<br><br>* Гариза бирүче булып торган юридик зат турында Бердәм дәүләт юридик затлар реестрыннан өземтә |
| 50. | Җир кодексының 39.9 статьясындагы 2 пунктның 4 пунктчасы | Даими (сроксыз) файдалануга | Үз вәкаләтләрен үтәүне туктаткан Россия Федерациясе Президентының тарихи мирас үзәге | Үз вәкаләтләрен үтәүне туктаткан Россия Федерациясе Президентының тарихи мирас үзәге эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен кирәкле җир участогы | Җир участогыннан файдалану максатлары нигезендә җир участогы бирүгә гариза бирүченең хокукын раслый торган, әлеге исемлек белән каралган документлар<br><br>* Күчемсез милек объекты турында (сорала торган җир участогы турында) Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрыннан өземтә<br><br>* Гариза бирүче булып торган юридик зат турында Бердәм дәүләт юридик затлар реестрыннан өземтә |
| 51. | Җир кодексының 39.10 статьясындагы 2 пунктның 1 пунктчасы | Түләүсез файдалануга | Дәүләт хакимияте органы | Дәүләт хакимияте органнары тарафыннан үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен кирәкле җир участогы | Җир участогыннан файдалану максатлары нигезендә җир участогы бирүгә гариза бирүченең хокукын раслый торган, әлеге исемлек белән каралган документлар<br><br>* Күчемсез милек объекты турында (сорала торган җир участогы турында) Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрыннан өземтә<br><br>* Гариза бирүче булып торган юридик зат турында Бердәм дәүләт юридик затлар реестрыннан өземтә |
| 52. | Җир кодексының 39.10 статьясындагы 2 пунктның 1 пунктчасы | Түләүсез файдалануга | Җирле үзидарә органы | Җирле үзидарә органнары тарафыннан үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен кирәкле җир участогы | Җир участогыннан файдалану максатлары нигезендә җир участогы бирүгә гариза бирүченең хокукын раслый торган, әлеге исемлек белән каралган документлар<br><br>* Күчемсез милек объекты турында (сорала торган җир |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | участогы турында) Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрыннан өземтә<br><br>* Гариза бирүче булып торган юридик зат турында Бердәм дәүләт юридик затлар реестрыннан өземтә |
| 53. | Җир кодексының 39.10 статьясындагы 2 пунктның 1 пунктчасы | Түләүсез файдалануга | Дәүләт яки муниципаль учреждение (бюджет, казна, автоном) | Дәүләт яки муниципаль учреждение (бюджет, казна, автоном) эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен кирәкле җир участогы | Җир участогыннан файдалану максатлары нигезендә җир участогы бирүгә гариза бирүченең хокукынраслый торган, әлеге исемлек белән каралган документлар<br><br>* Күчемсез милек объекты турында (сорала торган җир участогы турында) Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрыннан өземтә<br><br>* Гариза бирүче булып торган юридик зат турында Бердәм дәүләт юридик затлар реестрыннан өземтә |
| 54. | Җир кодексының 39.10 статьясындагы 2 пунктның 1 пунктчасы | Түләүсез файдалануга | Казна предприятиесе | Казна предприятиесе эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен кирәкле җир участогы | Җир участогыннан файдалану максатлары нигезендә җир участогы бирүгә гариза бирүченең хокукын раслый торган, әлеге исемлек белән каралган документлар<br><br>* Күчемсез милек объекты турында (сорала торган җир участогы турында) Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрыннан өземтә<br><br>* Гариза бирүче булып торган юридик зат турында Бердәм дәүләт юридик затлар реестрыннан өземтә |
| 55. | Җир кодексының 39.10 статьясындагы 2 пунктның 1 пунктчасы | Түләүсез файдалануга | Үз вәкаләтләрен үтәүне туктаткан Россия Федерациясе Президентының тарихи мирас үзәге | Үз вәкаләтләрен үтәүне туктаткан Россия Федерациясе Президентының тарихи мирас үзәге эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен кирәкле җир участогы | Җир участогыннан файдалану максатлары нигезендә җир участогы бирүгә гариза бирүченең хокукын раслый торган, әлеге исемлек белән каралган документлар<br><br>* Күчемсез милек объекты турында (сорала торган җир участогы турында) Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрыннан өземтә<br><br>* Гариза бирүче булып торган юридик зат турында Бердәм дәүләт юридик затлар реестрыннан өземтә |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 56. | Җир кодексының 39.10 статьясындагы 2 пунктның 2 пунктчасы | Түләүсез файдалануга | Җир участогы даими (сроксыз) файдалану хокукында бирелгән оешма хезмәткәре | Хезмәт урынындагы җир участогы рәвешендә бирелә торган җир участогы | Эшкә кабул итү турында боерык, хезмәт килешүе (контракт) (яисә хезмәт эшчәнлеге турында мәгълүмат) яки хезмәт кенәгәсеннән өземтә<br><br>* Күчемсез милек объекты турында (сорала торган җир участогы турында) Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрыннан өземтә |
| 57. | Җир кодексының 39.10 статьясындагы 2 пунктның 3 пунктчасы | Түләүсез файдалануга | Дини оешма | Дини яки хәйрия билгеләнешендәге биналар, корылмалар урнаштыру өчен билгеләнгән җир участогы | Мондый бинага, корылмага хокук Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрында теркәлмәгән очракта, гариза бирүченең бинага, корылмага хокукын раслаучы (билгеләүче) документлар (бина, корылма төзелгән очракта таләп ителми)<br><br>* Күчемсез милек объекты турында (сорала торган җир участогы турында) Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрыннан өземтә<br><br>* Сорала торган җир участогында урнашкан күчемсез милек объекты турында (бина һәм (яки) корылма турында) Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрыннан өземтә (бина, корылма төзелгән очракта таләп ителми)<br><br>* Гариза бирүче булып торган юридик зат турында Бердәм дәүләт юридик затлар реестрыннан өземтә |
| 58. | Җир кодексының 39.10 статьясындагы 2 пунктның 4 пунктчасы | Түләүсез файдалануга | Биналар, корылмалар түләүсез файдалану хокукында бирелгән дини оешма | Дини оешмага түләүсез файдалану хокукында бирелгән биналар, корылмалар урнашкан җир участогы | Мондый бинага, корылмага хокук Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрында теркәлмәгән очракта, бинадан, корылмадан түләүсез файдалану шартнамәсе<br><br>Мондый җир участогына хокук, (җир участогына тиешле хокуклар булганда) Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрында теркәлмәгән очракта гариза бирүченең сорала торган җир участогына хокукын раслаучы (билгеләүче) документлар)<br><br>Гариза бирүченең (гариза бирүчеләрнең) сорала торган җир участогында урнашкан барлык биналар, корылмалар исемлеге, кадастр (шартлы, инвентарь) номерлары һәм гариза бирүчегә тиешле хокукта карый торган биналарның, корылмаларның адреслы ориентирлары күрсәтелгән хәбәре |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | * Күчемсез милек объекты турында (сорала торган җир участогы турында) Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрыннан өземтә<br><br>* Күчемсез милек объекты (сорала торган җир участогында урнашкан бина һәм (яки) корылма турында) Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрыннаннан өземтә<br><br>* Гариза бирүче булып торган юридик зат турында Бердәм дәүләт юридик затлар реестрыннан өземтә |
| 59. | Җир кодексының 39.10 статьясындагы 2 пунктның 5 пунктчасы | Түләүсез файдалануга | «Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында» 2013 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә тулысынча федераль бюджет акчалары, Россия Федерациясе субъекты бюджеты акчалары яки җирле бюджет акчалары хисабына гамәлгә ашырыла торган күчемсез милек объектларын төзүгә яки реконструкцияләүгә граждан-хокукый шартнамә төзелгән зат | Тулысынча федераль бюджет, Россия Федерациясе субъекты бюджеты яки җирле бюджет акчалары хисабына гамәлгә ашырыла торган күчемсез милек объектларын төзү яки реконструкцияләү өчен билгеләнгән җир участогы | Тулысынча федераль бюджет акчалары, Россия Федерациясе субъекты бюджеты акчалары яки җирле бюджет акчалары хисабына гамәлгә ашырыла торган күчемсез милек объектларын төзүгә яки реконструкцияләүгә граждан-хокукый шартнамәләр<br><br>* Күчемсез милек объекты турында (сорала торган җир участогы турында) Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрыннан өземтә<br><br>* Гариза бирүче булып торган юридик зат турында Бердәм дәүләт юридик затлар реестрыннан өземтә |
| 60. | Җир кодексының 39.3 статьясындагы 2 пунктының 10 пунктчасы, 39.6 статьясындагы 2 пунктының 15 пунктчасы, 39.10 статьясындагы 2 пунктының 6 пунктчасы | Түләү нигезендә милеккә, арендага, түләүсез файдалануга | Индивидуаль торак төзелеше, шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару яки аның эшчәнлеген крестьян (фермер) хуҗалыгы тарафыннан гамәлгә ашыру өчен җир участогы сораучы граждан, аның эшчәнлеген крестьян (фермер) хуҗалыгы тарафыннан гамәлгә ашыру | Индивидуаль торак төзелеше, шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару яки крестьян (фермер) хуҗалыгы тарафыннан аның эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән җир участогы | Фермер хуҗалыгы берничә граждан (аның эшчәнлеге крестьян (фермер) хуҗалыгы тарафыннан гамәлгә ашырылган очракта) тарафыннан төзелгән очракта, крестьян (фермер) хуҗалыгын төзү турында килешү<br><br>* Күчемсез милек объекты турында (сорала торган җир участогы турында) Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрыннан өземтә |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | өчен җир участогы сораучы крестьян (фермер) хуҗалыгы | | * Гариза бирүче булып торган юридик зат турында Бердәм дәүләт юридик затлар реестрыннан өземтә<br><br>* Гариза бирүче булып торган шәхси эшмәкәр турында Бердәм дәүләт шәхси эшмәкәрләр реестрыннан өземтә |
| 61. | Җир кодексының 39.10 статьясындагы 2 пунктның 7 пунктчасы | Түләүсез файдалануга | Төп эш урыны буенча муниципаль берәмлектә һәм Россия Федерациясе субъекты законы белән билгеләнгән белгечлек буенча эшләүче граждан | Россия Федерациясе субъекты законы белән билгеләнгән муниципаль берәмлектә урнашкан, индивидуаль торак төзелеше яки шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен билгеләнгән җир участогы | Эшкә кабул итү турында боерык, хезмәт кенәгәсеннән өземтә (яисә хезмәт эшчәнлеге турында мәгълүмат) яки хезмәт килешүе (контракт)<br><br>* Күчемсез милек объекты турында (сорала торган җир участогы турында) Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрыннан өземтә |
| 62. | Җир кодексының 39.10 статьясындагы 2 пунктның 8 пунктчасы | Түләүсез файдалануга | Торак йорт рәвешендә эш урыныннан торак урын бирелгән граждан | Торак йорт рәвешендә эш урыныннан бирелә торган торак урын урнашкан җир участогы | Хезмәт урыныннан бирелә торган торак урынны наемга алу шартнамәсе<br><br>* Күчемсез милек объекты турында (сорала торган җир участогы турында) Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрыннан өземтә |
| 63. | Җир кодексының 39.10 статьясындагы 2 пунктның 9 пунктчасы | Түләүсез файдалануга | Үз ихтыяҗлары өчен авыл хуҗалыгы эшчәнлеге (шул исәптән умартачылык) өчен җир участогы сораучы граждан | Урман участогы | * Күчемсез милек объекты турында (сорала торган җир участогы турында) Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрыннан өземтә |
| 64. | Җир кодексының 39.10 статьясындагы 2 пунктның 11 пунктчасы | Түләүсез файдалануга | Авыл хуҗалыгы, аучылык хуҗалыгы, урман хуҗалыгы һәм башкача файдалану өчен, биналар, корылмалар төзүне күздә тотмый торган җир участогы сораучы граждан яки юридик зат | Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән тәртиптә расланган оборона һәм куркынычсызлык ихтыяҗлары өчен бирелгән һәм күрсәтелгән ихтыяҗлар өчен вакытлыча файдаланылмый торган җир участоклары исемлегенә кертелгән җир участогы | * Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән тәртиптә расланган оборона һәм куркынычсызлык ихтыяҗлары өчен бирелгән һәм күрсәтелгән ихтыяҗлар өчен вакытлыча файдаланылмый торган җир участоклары исемлеге<br><br>* Күчемсез милек объекты турында (сорала торган җир участогы турында) Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрыннан өземтә<br><br>* Гариза бирүче булып торган юридик зат турында Бердәм дәүләт юридик затлар реестрыннан өземтә |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | * Гариза бирүче булып торган шәхси эшмәкәр турында Бердәм дәүләт шәхси эшмәкәрләр реестрыннан өземтә |
| 65. | Җир кодексының 39.10 статьясындагы 2 пунктның 11 пунктчасы | Түләүсез файдалануга | СНТ яки ОНТ | Гражданнар тарафыннан үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык яки яшелчәчелек алып бару өчен билгеләнгән җир участогы | Гражданнар тарафыннан үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык яки яшелчәчелек алып бару өчен билгеләнгән җир участогыннан түләүсез файдалану хокукын алу турында ширкәт әгъзаларының гомуми җыелышы карары<br><br>* Күчемсез милек объекты турында (сорала торган җир участогы турында) Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрыннан өземтә<br><br>* СНТ яки ОНТга карата Бердәм дәүләт юридик затлар реестрыннан өземтә |
| 66. | Җир кодексының 39.10 статьясындагы 2 пунктның 12 пунктчасы | Түләүсез файдалануга | Торак төзелеше максатларында гражданнар тарафыннан төзелгән коммерцияле булмаган оешма | Торак төзелеше өчен билгеләнгән җир участогы | Коммерцияле булмаган оешма төзү турында карар<br><br>* Күчемсез милек объекты турында (сорала торган җир участогы турында) Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрыннан өземтә<br><br>* Гариза бирүче булып торган юридик зат турында Бердәм дәүләт юридик затлар реестрыннан өземтә |
| 67. | Җир кодексының 39.10 статьясындагы 2 пунктның 14 пунктчасы | Түләүсез файдалануга | «Дәүләт оборона заказы турында» 2012 елның 29 декабрендәге 275-ФЗ номерлы Федераль закон яки «Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәтләр күрсәтүне сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында» 05.04.2013 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, тулысынча федераль бюджет акчалары хисабына гамәлгә ашырыла торган ил оборонасын һәм дәүләт иминлеген тәэмин итү өчен | «Дәүләт оборона заказы турында» 2012 елның 29 декабрендәге 275-ФЗ номерлы Федераль закон яки «Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәтләр күрсәтүне сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында» 05.04.2013 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә төзелгән дәүләт контрактында каралган эшләрне башкару яки хезмәтләр күрсәтү өчен кирәкле җир участогы | Дәүләт контракты<br><br>* Күчемсез милек объекты турында (сорала торган җир участогы турында) Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрыннан өземтә<br>* Гариза бирүче булып торган юридик зат турында Бердәм дәүләт юридик затлар реестрыннан өземтә |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | эшләр башкаруга, хезмәтләр күрсәтүгә дәүләт контракты төзелгән зат | | |
| 68. | Җир кодексының 39.10 статьясындагы 2 пунктның 15 пунктчасы | Түләүсез файдалануга | Гражданнарның аерым категорияләрен торак урыннары белән тәэмин итү өчен торак төзелеше максатларында Россия Федерациясе субъекты законы белән каралган һәм Россия Федерациясе субъекты тарафыннан төзелгән коммерцияле булмаган оешма | Торак төзелеше өчен билгеләнгән җир участогы | Коммерцияле булмаган оешма төзү турында Россия Федерациясе субъекты карары<br><br>* Күчемсез милек объекты турында (сорала торган җир участогы турында) Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрыннан өземтә<br><br>* Гариза бирүче булып торган юридик зат турында Бердәм дәүләт юридик затлар реестрыннан өземтә |
| 69. | Җир кодексының 39.10 статьясындагы 2 пунктның 16 пунктчасы | Түләүсез файдалануга | Дәүләт яки муниципаль ихтыяҗлар өчен тартып алуга бәйле рәвештә, дәүләт яки муниципаль милектәге җир участогына түләүсез файдалану хокукы туктатылган булган зат | Дәүләт яки муниципаль ихтыяҗлар өчен тартып алынган җир участогы урынына бирелә торган җир участогы | Дәүләт яки муниципаль ихтыяҗлар өчен җир участогын тартып алу турында килешү яки дәүләт яки муниципаль ихтыяҗлар өчен җир участогын тартып алу өчен нигез булып торган суд карары<br><br>* Күчемсез милек объекты турында (сорала торган җир участогы турында) Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрыннан өземтә<br><br>* Гариза бирүче булып торган юридик зат турында Бердәм дәүләт юридик затлар реестрыннан өземтә |

"*" символы белән билгеләнгән документлар муниципаль милектәге җир участоклары белән идарә итүгә вәкаләтле орган (алга таба – вәкаләтле орган) тарафыннан ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек аша соратып алына. Күчемсез милек объекты турында (сорала торган җир участогы турында) Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрыннан өземтә җир участогына хокуклар алу турында гаризага теркәлми һәм сорала торган җир участогын булдыру кирәк булган очракта, җир участогы бирүне алдан килештереп җир участогы биргәндә, вәкаләтле орган тарафыннан ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек аша соратып алынмый. Бинага, корылмага, төзелеше тәмамланмаган объектка хокук, әлеге хокук Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрында дәүләт теркәвенә алынган вакытка бәйсез рәвештә федераль закон нигезендә барлыкка килгән дип саналган очракта, күчемсез милек объекты турында (сорала торган җир участогында урнашкан бина, корылма яки төзелеше тәмамланмаган объект турында) Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрыннан өземтә җир участогына хокуклар алу турындагы гаризага теркәлми һәм вәкаләтле орган тарафыннан ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек аша соратып алынмый.

Муниципаль милектәге җир участогын сатулар үткәрмичә милеккә, арендага, даими (сроксыз) файдалануга, түләүсез файдалануга бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына
2 нче кушымта

Җир участогын сату-алу шартнамәсе формасы

Муниципаль районда, шәһәр округында расланган форма

Милекчеләргә җир участогын, җир участогында урнашкан биналарны, корылмаларны сату-алу шартнамәсе

№________________

Яр Чаллы шәһәре «____»_____________20___ ел

«Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты» муниципаль казна учреждениеесе Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге исеменнән, Башкарма комитет Җитәкчесе ______________________________ йөзендә, Устав нигезендә эш итүче, алга таба бер яктан «Сатучы» дип аталучы, һәм

____________________________________________________________________________
юридик затның исеме яисә гражданның фамилиясе, исеме, атасының исеме

икенче яктан «Сатып алучы» дип аталучы,_______________________________________________________________
устав, гамәлгә кую шартнамәсе, ышаныч язуы

алга таба «Яклар» дип аталучы яклар ______________________________________________

Россия Федерациясе Граждан кодексы, Россия Федерациясе Җир кодексы, «Россия Федерациясе Җир кодексын гамәлгә кертү турында» гы 2001 елның 25 октябрендәге 137-ФЗ номерлы Федераль законы нигезендә, түбәндәгеләр турында алга таба «Шартнамә» дип аталучы әлеге шартнамәне төзеделәр.

1. Шартнамә предметы

1.1. Сатучы милеккә бирергә бурычлы, ә Сатып алучы, гомуми мәйданы _____ кв. м, кадастр номеры___________________ җирләрнең категориясе: ___________________.булган җир участогын Шартнамә шартларында кабул итәргә һәм түләргә бурычлы.

1.2. Җир участогының урнашу адресы:

___________________________________________________________________________.

1.3. Җир участогы тасвирламасы:

1.3.1. җир участогында урнашкан:

_______________________________________________________________________________
(бина, корылма исеме, адрес, кадастр номеры)

1.3.2. җир участогына хокукларны чикләүләр һәм каршылыклар билгеләнде _________________________________, ул Шартнамәнең аерылгысыз өлеше булып тора.

1.3.3. башкалар: ____________________________________________

1.4. Җир участогыннан рөхсәт ителгән файдалану: ____________________________________________.

Җир участогыннан рөхсәт ителгән файдалану төренең күрсәтелгән тасвирламасы тәмамланган булып тора һәм Сатып алучы аны үзгәртергә тиеш түгел.

1.5. Шартнамәне имзалаган вакытта Якларның җир участогының торышына һәм аның характеристикаларына карата дәгъвалары юк.

2. Шартнамә буенча түләү һәм исәп-хисап тәртибе

2.1. Җир участогының бәясе ______________________________

2.2. Сатып алучы җир участогының бәясен Шартнамә имзаланган көннән башлап 30 (*утыз*) календарь көн эчендә түли.

2.3. Шартнамә буенча түләнергә тиешле сумма счетка күчерелә:

______________________________________

(түләү реквизитлары)

2.4. Сатып алучы тарафыннан җир участогының үзәкләштерелгән үзгәртү, башка кадастр бәясен кертү турындагы Шартнамәнең 2.2 пунктын үтәү срогы чыккан очракта, шулай ук җир участогы бәясен исәпләгәндә исәпкә алына торган башка ставкаларны, нормативларны, коэффициентларны керткәндә, Сатучы Сатып алучыдан түләүне таләп итәргә хокуклы, ә Сатып алучы Шартнамә буенча әлеге үзгәрешләрне исәпкә алып, җир участогының бәясен түләргә бурычлы.

3. Якларның бурычлары

3.1. Сатучы бурычлы:

3.1.1. Шартнамәнең 5.4 пунктында каралган очракта, Шартнамәне өзү турында хокукларны теркәүче органга хәбәр итү.

3.2. Сатып алучы бурычлы:

3.2.1. Шартнамәнең 2.1-2.4 пунктларында билгеләнгән срокта һәм тәртиптә җир участогы бәясен түләү.

3.2.2. Сатучыга банк раслаган җир участогы бәясен түләү турындагы түләү документының күчермәсен түләү вакытыннан башлап 5 календарь көн эчендә тапшыру.

3.2.3. Җир участогыннан файдалану буенча гамәлдәге законнар нигезендә билгеләнгән чикләүләрдән килеп чыга торган таләпләрне үтәү.

3.2.4. Җир участогында межалау һәм геодезия билгеләрен урнаштыруны, шулай ук аларга бару, инфраструктура объектларын төзекләндерү, реконструкцияләү, ремонтлау өчен тиешле хезмәтләрнең җир участогына керүен тәэмин итү.

3.2.5. Җир участогының, җир участогындагы һәм якын-тирә территориядәге экологик хәлнең сыйфат характеристикасы начарлануга китерә торган гамәлләр кылмау.

3.2.6. Сатучыга һәм дәүләт һәм муниципаль җир контроле органнарына җир участогын карау, Шартнамәнең шартларын үтәүне тикшерү өчен җир участогына ирекле керү мөмкинлеген тәэмин итү.

3.2.7. Шартнамәне имзалаганнан соң һәм җир участогына милек хокукын теркәү вакытына кадәр аның җир участогындагы күчемсез милеген өченче затлар өчен милеккә алып булмый.

## 4. Җир участогына милек хокукы барлыкка килү

4.1. Җир участогына милек хокукы Сатып алучыдан җир участогына хокукларны теркәүне гамәлгә ашыра торган органда милек хокукы күчүне дәүләт теркәвенә алган вакыттан башлап барлыкка килә.

## 5. Якларның җаваплылыгы

5.1. Яклар килешүе буенча җир участогына каршылыклар һәм аны гамәлдәге законнарда каралган тәртиптә файдалануны чикләү турында белә торып ялган мәгълүмат биргән өчен җаваплы.

5.2. Сатып алучы өченче затлар алдында милек хокукында булган һәм җир участогында урнашкан күчемсез милекне җир участогын милеккә алу өчен гариза биргән көннән башлап җир участогына милек хокукын дәүләт теркәвенә алганчы тартып алу нәтиҗәләре өчен җавап тота.

5.3. Яклар гамәлдәге законнар нигезендә килешү шартларын үтәмәгән яисә тиешенчә үтәмәгән өчен җаваплы.

5.4. Сатып алучы тарафыннан түләү срогы чыккан очракта, 15 календарь көн эчендә Сатучы Сатып алучыга тиешле белдерү кәгазе җибәргән вакыттан башлап 30 календарь көн узгач, РФ Граждан кодексының 450.1 статьясындагы 2 пункт таләпләре нигезендә, Шартнамә өзелгән дип санала.

## 6. Башка шартлар

6.1. Шартнамәгә кертелгән барлык үзгәрешләр һәм өстәмәләр, әгәр алар язма рәвештә башкарылган һәм вәкаләтле затлар тарафыннан имзаланган булса, гамәлдә санала.

6.2. Шартнамәдә җайга салынмаган барлык башка мәсьәләләр буенча да Яклар гамәлдәге законнар нормаларына таяна.

6.3. Шартнамә бер үк юридик көчкә ия булган, Сатучыда, Сатып алучыда һәм хокукларны теркәүне гамәлгә ашыра торган органда саклана торган ____ нөсхәдә төзелде.

6.4. Шартнамәнең аерылгысыз өлеше булып тора:

- җир участогын кабул итү-тапшыру акты.
- Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрыннан күчемсез милек объекты турында өземтә.

Якларның адреслары һәм башка реквизитлары:

| Сатучы: | Сатып алучы: |
| --- | --- |
| «ТР Яр Чаллы шәһәре<br>муниципаль берәмлеге<br>Башкарма комитеты»<br>муниципаль казна учреждениесе<br>мберәмлек башлыгы<br>Адрес: 423805, Татарстан Республикасы,<br>Яр Чаллы шәһәре,<br>Х. Туфан проспекты, 23 йорт<br>ИНН: 1650135166/165001<br>БИК: 049205001 ОГРН: 1051614258740 | |

Якларның имзалары

| | |
|---|---|
| Сатучы<br>Башкарма комитет<br>Җитәкчесе | Сатып алучы |
| _____________________________<br>М.У. | _____________________________<br>М.У. (булганда) |

ҖИР УЧАСТОГЫН КАБУЛ ИТҮ-ТАПШЫРУ
АКТЫ

Яр Чаллы шәһәре
«_____»_________20___ ел

«Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты» муниципаль казна учреждениесе Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге исеменнән, Башкарма комитет Җитәкчесе ____________________________ йөзендә, Устав нигезендә эш итүче, алга таба бер яктан «Сатучы» дип аталучы, һәм

_______________________________________________________________________________

гражданның фамилиясе, исеме, атасының исеме

икенче яктан «Сатып алучы» дип аталучы

түбәндәге адрес буенча урнашкан җир участогын кабул итә:
______________________________, рөхсәт ителгән куллану төре белән:
______________________ җирләрнең категориясе: ____________________.

Сатып алучының тапшырыла торган җир участогына дәгъвалары юк.

Якларның адреслары һәм башка реквизитлары:

| Сатучы: | Сатып алучы: |
| --- | --- |
| «ТР Яр Чаллы шәһәре<br>муниципаль берәмлеге<br>Башкарма комитеты»<br>муниципаль казна учреждениесе<br>Адрес: 423805, Татарстан Республикасы,<br>Яр Чаллы шәһәре,<br>Х. Туфан проспекты, 23 йорт<br>ИНН: 1650135166/165001<br>БИК: 049205001 ОГРН: 1051614258740 | |

Якларның имзалары

| Сатучы<br>Башкарма комитет<br>Җитәкчесе | Сатып алучы |
| --- | --- |
| ________________________________<br>М.У. | ________________________________<br>М.У. (булганда) |

Муниципаль милектәге җир участогын сатулар үткәрмичә милеккә, арендага, даими (сроксыз) файдалануга, түләүсез файдалануга бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына
3 нче кушымта

Җир участогын арендалау шартнамәсе формасы

Муниципаль районда, шәһәр округында расланган форма

Җир участогын арендага алу
шартнамәсе
№_______________

Яр Чаллы шәһәре «____»___________20___ ел

«Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты» муниципаль казна учреждениесе, Башкарма комитет Җитәкчесе ______________________ йөзендә, шәһәр Уставы нигезендә эш итүче, алга таба бер яктан «Арендага бирүче» дип аталучы, һәм

__________________________
(юридик затның исеме яисә гражданның фамилиясе, исеме, атасының исеме)

икенче яктан «Арендатор» дип аталучы, Арендаторның гаризасы нигезендә, __________________*туры китереп,* түбәндәгеләр турында әлеге шартнамәне (алга таба – Шартнамә) төзеделәр:

1. Шартнамә предметы

1.1. Арендага бирүче ________________________________ адресы буенча урнашкан, мәйданы __________ кв. м , кадастр номеры ________________ булган җир участогын тапшыра, ә Арендатор кабул итә һәм аны аренда шартларында файдалана: ____________________________________________ (алга таба – җир участогы).

1.2. Җир участогы ______________җирләренә карый:
1.3. ______________________________________________________________________
(биналар, корылмалар, аларның характеристикалары)
җир участогында урнашкан: (алга таба – Объект).
___________________________________________________________________________
(табигать һәм тарихи-мәдәни һәйкәлләр)

1.4. Җир участогыннан рөхсәт ителгән файдалану: ________________________________________

Җир участогыннан файдалануның күрсәтелгән рөхсәт ителгән төре ахыргы дип санала һәм ул Арендатор тарафыннан үзгәртелергә тиеш түгел.

1.5. Җир участогы __________________________ йөкләнеше (сервитут).
(чикләнгән яисә чикләнмәгән)

## 2. Шартнамәнең гамәлдәге срогы

2.1. Шартнамә төзелгән срок ________________________________ ел
(аренда вакыты)

2.2. Шартнамә срогы башлану Арендага бирүче тарафыннан Шартнамәгә һәм җир участогын кабул-итү-тапшыру актын имзалау датасыннан исәпләнә.

2.3. Шартнамә җир участогын кабул итү-тапшыру акты буенча тапшырганнан соң төзелгән дип санала һәм мәҗбүри дәүләт теркәвенә алынырга тиеш.

